# РУС ТЕЛЕНДӘ
# УРТА (ТУЛЫ) ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕНДӘ
# ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ ПРОГРАММАСЫ

***(рус телендә сөйләшүче балалар өчен)***

**1—11 нче СЫЙНЫФЛАР**

**Төзүче-авторлары:**

***К. С. Фәтхуллова,***
педагогика фәннәре кандидаты, доцент

***Ф. Х. Җәүһәрова,***
филология фәннәре кандидаты, доцент

# БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 нче маддәсе нигезендә татар һәм рус телләре — тигез хокуклы дәүләт телләре. Күп милләтле Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә. Татар теле, дәүләт теле буларак, барлык урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә төп укыту фәннәренең берсе булып тора. Программа татар телен аралашу чарасы буларак укытуны тәэмин итәргә тиеш. Татар телен дәүләт теле буларак укытуның гомуми максаты — укучыларда **коммуникатив компетенция** (аралашу осталыгы) формалаштыру. **Компетенция** — аралашуны тәэмин итә торган белем, күнекмәләр һәм осталыклар бердәмлеге ул. **Коммуникатив компетенция** — аралашу максатын, урынын, вакытын, анда катнашучыларның социаль хәлен исәпкә алып, фикерне төгәл һәм эзлекле итеп белдерә алу осталыгы ул. Моңа бәйле рәвештә татар теленә өйрәтүдә аңлы-коммуникатив методка өстенлек бирелергә тиеш.

Гомуми башлангыч белем мәктәбендә татар теленә өйрәтүнең төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) **гамәли максат,** ягъни татар теленең фонетик, лексик, грамматик берәмлекләрен гамәли үзләштерү һәм укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерүгә ирешү; 2) **гомуми белем бирү максаты** — укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерү; 3) **тәрбияви максат** — балаларның рухи дөньясын баету, аларда шәхесара һәм мәдәниятара аралашу күнекмәләре булдыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләү.

Куелган максатларга ирешү өчен, аерым бурычларны хәл итү сорала. Гамәли максатка ирешү өчен, укучыларны татар сөйләмен тыңлап аңларга, диалогик һәм монологик формада аралашырга, төрле жанрлардагы татар текстларын сәнгатьле итеп һәм аңлап укырга, татар теленең фонетик, лексик, грамматик нигезләрен гамәли үзләштереп, сөйләм булдырырга күнектерү бурычлары куела. Гомуми белем бирү һәм тәрбияви максатларга ирешү өчен, укучыларның акыл хезмәте күнекмәләрен үстерү, татар сөйләм этикеты үрнәкләрен урынлы кулланырга өйрәтү, татар дөньясы, шул исәптән татар халкының гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру сорала.

Татар теленә өйрәтү беренче чиратта *фәннилек, аңлылык, аңлаешлылык, системалылык, эзлеклелек, күрсәтмәлелек, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу* кебек гомумдидактик принципларга

нигезләнә. Моннан тыш, коммуникатив методның нигезен тәшкил иткән *телгә өйрәтүне гамәли эшчәнлеккә юнәлтү, тел һәм сөйләм берәмлекләрен сайлау һәм өйрәтүгә функциональ якын килү, тел берәмлекләрен концентрик рәвештә урнаштыру һәм этаплап өйрәтү, тел берәмлекләрен ситуатив-тематик нигездә өйрәтү, лексик-грамматик материалны синтаксик нигездә үзләштерү, укучыларның ана теле үзенчәлекләрен исәпкә алу* принципларын да истә тотып эш итү таләп ителә. Гомуми башлангыч белем мәктәбендә татар теле дәресләре укучыларның гамәли белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен, аралашу осталыкларын үстерүгә юнәлтелергә тиеш. Бу исә сөйләм эшчәнлегенең төрләренә — тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язуга үзара бәйләнештә һәм системалы өйрәтүне үз эченә ала.

**Тыңлап аңлауга** өйрәтү барышында укучылар, аерым сүзләрне, җөмләләрне һәм бәйләнешле текстларны ишетеп, аларның әйтелешен, мәгънәләрен һәм эчтәлекләрен аңларга күнегергә тиешләр. Башлангыч сыйныфларда укучыларны, укытучының һәм сыйныфташларының сөйләмен яки аудиокушымтадагы татар сөйләмен тыңлап, эчтәлегенә төшенеп барырга, кирәкле мәгълүматны аерып, сорауларга җавап бирергә, әңгәмә корырга, эчтәлекне татарча сөйләп бирергә күнектерү мөһим.

**Диалогик сөйләмгә** өйрәткәндә, укучыларның мәктәптәге һәм җәмәгать урыннарындагы тормышына бәйле диалогларны сәнгатьле итеп уку һәм яттан сөйләү, охшаш диалог төзү эшләренә өстенлек бирү әһәмияткә ия. Алар аша укучылар татар сөйләм этикеты үрнәкләрен, тотрыклы сөйләм гыйбарәләрен, реплика төрләрен актив рәвештә үзләштерә алалар. Уку аралашуы чын аралашуга китерсен өчен, балаларны үз фикерләрен төгәл һәм дөрес итеп белдерергә өйрәтү зарур.

**Монологик сөйләмгә** өйрәтү кешеләрне, предметларны, табигать күренешләрен, хайваннарны тасвирлауга, шулай ук мәктәп, шәһәр (авыл), гаилә һәм башка темаларга хикәя төзеп сөйләүгә, укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген сөйләп бирүгә кайтып кала. Укучыларда монологик сөйләм күнекмәләре үсеш алсын өчен, аларны билгеле бер ситуациягә бәйле җөмләләр төзеп әйтергә, аларны үзара бәйләргә һәм логик яктан эзлекле текст төзергә әзерләү кирәк.

**Укуга өйрәткәндә,** укучылар башта татар хәрефләрен танып, алар белдергән авазларны дөрес әйтү; тартыкны сузыкка ияртеп, кыска сүзләрне бөтен килеш, озын сүзләрне иҗекләп уку, алга таба җөмләләрне һәм бәйләнешле текстларны сәнгатьле итеп һәм аңлап уку; укылганның эчтәлегенә төшенеп бару, яңа сүзләрнең мәгънәләрен контексттан чыгып аңлау яки сүзлектән табу күнекмәләренә ия булырга тиешләр. Моңа ирешү өчен, башлангыч чорда ситуатив-тематик яки грамматик нигездә төркемләнгән сүзләр һәм сүзтезмәләр, җөмләләр яисә бәйләнешле уку текстлары белән эш итәргә кирәк. Алар укучыларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып сайланырга һәм тәрбияви яктан әһәмиятле булырга тиеш. Алга таба таныш материалга нигезләнгән кечкенә күләмле текстларны, шулай ук таныш булмаган сүзләр кергән текстларны эчтән аңлап укырга, кирәкле мәгълүматны

табарга, сүзлекләрдән файдаланырга өйрәтү мөһим. Шулай ук укучылар, шигырьләрне яттан өйрәнеп, сәнгатьле итеп сөйли белергә тиешләр. Башлангыч сыйныфларда *кычкырып уку* һәм *эчтән уку* төрләренә өстенлек бирелә. Моннан тыш, *карап чыгу максаты белән уку, өйрәнү максаты белән уку, танышу максаты белән уку, эзләнү максаты белән уку* төрләрен куллану да әһәмияткә ия.

**Язуга өйрәтү** татар алфавитындагы хәрефләрнең язылышын истә калдыру; сүзләрне иҗекләргә бүлеп, юлдан-юлга дөрес күчереп язу кагыйдәләрен үзләштерү; сөйләмдә актив кулланыла торган сүзләрне орфографик дөрес язу күнекмәләрен үстерүдән гыйбарәт. Моңа ирешү өчен, җөмләләрне яки текстны үзгәрешсез күчереп язу (1—2 нче сыйныфлар); нокталар урынына кирәкле сүзләрне яки җәяләр эчендә бирелгән сүзләрне кирәкле формада куеп, җөмләләрне күчереп язу (3—4 нче сыйныфлар) кебек эш төрләрен куллану зарур.

**Язма сөйләмгә өйрәтү** терәк сүзләр яки сүзтезмәләр белән лексик тема яки ситуация буенча җөмләләр һәм кечкенә хикәяләр язуны үз эченә ала. Аерым җөмләләрдән бәйләнешле язма сөйләмгә күчелә. Укучыларны үзләренең гаиләләре, мәктәпләре, сыйныфташлары һәм дуслары, яшәгән шәһәрләре яки авыллары турында кечкенә хикәяләр язарга өйрәтү мөһим. Котлау открыткасы яки хат язу, рус теленнән татарчага тәрҗемә итү эшләре дә укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерә. Шунысы мөһим: башлангыч сыйныфларда язма сөйләмгә караганда телдән сөйләмгә күбрәк игътибар бирелергә тиеш.

Дәресләрдә тел һәм сөйләм материалы аша татар халкының тормыш-көнкүреше, йолалары һәм гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре һәм ризыклары турында мәгълүмат җиткерү, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру балаларны әхлакый һәм эстетик яктан тәрбияли, аларның дөньяны танып белү мөмкинлекләрен арттыра.

Сөйләмнең фонетик, лексик, грамматик ягын үстерү өчен, беренче дәресләрдән үк авазларны — сүзләр аша, ә сүзләрне җөмләләр аша дөрес әйтергә күнектерү, актив үзләштерелгән җөмлә калыпларын бәйләнешле сөйләмгә кертергә өйрәтү шарт. Лексик минимумга килгәндә, башлангыч мәктәптә 1000 гә якын сүзне актив үзләштерү һәм сөйләмдә куллану күнекмәләре булдыру бурычы куела. Моның өчен кулланылыш ешлыгыннан чыгып сайланган сүзләр һәр сыйныфта тематик принципка нигезләнеп бирелә. Шулай ук укучылар, терминнарны атамыйча гына, мәгънәләре ягыннан якын (синонимнар), капма-каршы (антонимнар) яки әйтелешләре охшаш сүзләрне дә (омонимнар) гамәли үзләштерергә тиешләр. Грамматик минимумның эчтәлеген аралашу оештыру өчен кирәк булган тел берәмлекләре һәм аларның морфологик формалары, җөмлә калыплары тәшкил итә. Укучылар аларны сөйләм үрнәкләре аша гамәли үзләштерергә тиешләр. Орфоэпик-орфографик минимум исә аваз-хәреф мөнәсәбәтләрен, татар теленә хас булган үзенчәлекле авазларның һәм иҗек калыпларының әйтелешен, хикәя һәм сорау җөмлә интонациясен, сүз басымын гамәли үзләштерүне үз эченә ала.

1 нче сыйныфта татар телен укыту **телдән әзерлек чоры** белән башланып китә. Беренче чиректә балалар төрле аралашу ситуацияләренә бәйле җөмлә калыпларын күрсәтмәлелек аша үзләштерергә, аларны дөрес һәм аңлаешлы итеп әйтә белергә, укытучының сорауларына җавап бирә һәм кечкенә диалоглар (монологлар) төзеп сөйли алырга тиешләр. Телдән әзерлек чорында, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, санамышлар, тизәйткечләр, мәкальләр, кечкенә җырлар өйрәтү, төрле кызыклы уеннар куллану, физкультпаузалар үткәрү бигрәк тә мөһим. Һәрбер лексик теманы өйрәнгәннән соң, кабатлау дәресендә укучыларның белем һәм сөйләм күнекмәләрен тикшереп бару укытучының игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Башлангыч белем бирү мәктәбендә татар телен коммуникатив нигездә укыту, беренчедән, балаларда **тел компетенциясе** булдыруга китерә, чөнки алар тел берәмлекләрен гамәли үзләштереп, сөйләмдә кулланырга күнегәләр; икенчедән, аларның **сөйләм компетенциясе** үсеш ала, чөнки тел аралашу аша үзләштерелә; өченчедән, тел һәм сөйләм берәмлекләре аша татар дөньясы турындагы мәгълүматны үзләштереп, алар **социаль-мәдәни компетенциягә** ия булалар.

Укучыларда татар телен өйрәнүгә карата тотрыклы кызыксыну уяту һәм омтылыш тәрбияләү, аларның белемнәрен тагын да тирәнәйтү һәм укытуның сыйфатын яхшырту максатыннан, дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруга да тиешле игътибар бирү мөһим. Моның өчен иң яхшы шигырь сөйләүче яки иң яхшы җыр башкаручыга, иң яхшы рәсем ясаучы яки иң яхшы инша язучыга конкурслар, төрле викториналар уздыру; татар әкиятләрен сәхнәләштерү, татар биюләрен башкару, сыйныф газеталары чыгару, татар балалар шагыйрьләре белән очрашулар һәм кызыклы кичәләр үткәрү; курчак театрына бару, күренекле татар шәхесләренең музейларына экскурсияләр оештыру аеруча әһәмиятле. Мондый чаралар татар телен укытуны тагын да камилләштерүгә, аның нәтиҗәлелеген арттыруга китерә.

Башлангыч мәктәптә татар телен укыту өч этапка бүленә: **I** этап — 1 нче сыйныф (нигез салу этабы); **II** этап — 2—3 нче сыйныфлар (төп этап); **III** этап — 4 нче сыйныф (гомумиләштерү этабы).

# 1 нче СЫЙНЫФ (132 сәгать)

АРАЛАШУ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ТЕМАЛАРЫ

1. Исәнме, мәктәп!
2. Гаилә.
3. Сәламәт бул!
4. Шәһәрдә.
5. Уенчыклар кибетендә.
6. Киемнәр кибетендә.
7. Ашамлыклар кибетендә.
8. Ел фасыллары.
9. Яңа ел бәйрәме.
10. Без кунакка барабыз.
11. Без уйныйбыз, җырлыйбыз.
12. Йорт хайваннары һәм кошлары.
13. Кыргый хайваннар һәм кошлар.
14. Әниләр бәйрәме.
15. Бакчада.
16. Без спорт яратабыз.
17. Җәйге ял.

**ЛЕКСИК МИНИМУМ**

**1. Исәнме, мәктәп! (**8 сәгать)

исәнмесез, исәнме, сәлам, укучы, укытучы, малай, кыз, мәктәп, сыйныф, сыйныф бүлмәсе, дәрес, дәфтәр, китап, каләм, акбур, такта, бу, кем, нәрсә, әйе, юк, түгел, мин, син, ул, без, сез, алар, басарга, утырырга, укырга, нишләргә, рәхмәт, сау бул, сау булыгыз

**2. Гаилә** (8 сәгать)

гаилә, кеше, әти, әни, абый, апа, эне, сеңел, бала, әби, бабай, исем, тату, өй, фатир, кат, нинди, ничек, ничә, ничәнче, кайда, зур, кечкенә, яхшы, начар, кызык, яшь, шәһәр, авыл, бар, һәм, яшәргә, эшләргә, яратырга, карарга

**3. Сәламәт бул!** (8 сәгать)

баш, колак, чәч, борын, бит, күз, каш, керфек, тел, теш, ияк, муен, маңгай, кул, бармак, сул, уң, аяк, тарак, тararга, су, юарга, чистартырга, сәламәт булырга

**4. Шәһәрдә** (8 сәгать)

шәһәр, урам, йорт, мәйдан, һәйкәл, бина, ашханә, кунакханә, китапханә, кибет, базар, киң, тар, озын, кыска, биек, тәбәнәк, борынгы, чиста, матур, барырга, кайтырга, кая, кайдан, каян

**5. Уенчыклар кибетендә** (8 сәгать)

уенчык, йомшак, курчак, туп, шакмак, аю, төлке, песи, эт, алырга, бирергә, килергә, китәргә, әйтергә, кирәк (түгел), сатучы

**6. Киемнәр кибетендә** (8 сәгать)

кием, күлмәк, чалбар, итәк, тун, бүрек, бияләй, күн итек, шәл, яулык, кулъяулык, кесә, оекбаш, кияргә, салырга, кыйбат, арзан

**7. Ашамлыклар кибетендә** (8 сәгать)

икмәк, күмәч, сөт, чәй, конфет, май, шикәр, яшелчә, алма, минераль су, ашарга, эчәргә

**8. Ел фасыллары** (8 сәгать)

кыш, яз, җәй, көз, җылы, салкын, аяз, кар ява, кар бөртеге, болыт, кояш, җил исә, яңгыр, һава, хәзер, бүген, иртәгә, кичен, көндез

**9. Яңа ел бәйрәме** (8 сәгать)

бәйрәм, Яңа ел, бүләк, Кыш бабай, Кар кызы, чыршы, кар бабай ясарга, котларга, теләргә, бәхет, шатлык, тиздән, башланырга, бизәргә, эләргә

**10. Без кунакка барабыз** (8 сәгать)

кунак, чынаяк, пычак, кашык, калак, чәнечке, тәлинкә, бал, баллы, пешерергә, чәкчәк, гөбәдия, өчпочмак, кыстыбый, пәрәмәч, коймак

**11. Без уйныйбыз, җырлыйбыз** (8 сәгать)

уйнарга, җырларга, җыр, җырчы, биергә, көләргә, шатланырга, бию, биюче, шигырь, мәзәк, сөйләргә, гармун, курай, күңелле, турында, белән

**12. Йорт хайваннары һәм кошлары** (8 сәгать)

хайван, сыер, бозау, ат, колын, сарык, кәҗә, дуңгыз, кош, әтәч, тавык, каз, үрдәк, күркә, каз бәбкәсе, үрдәк бәбкәсе, чеби, кычкырырга, мияуларга, өрергә, чабарга

**13. Кыргый хайваннар һәм кошлар** (8 сәгать)

урман, кыргый, бүре, куян, керпе, тиен, поши, болан, усал, куркак, чыпчык, күгәрчен, карга, тукран, төс, ак, кара, кызыл, яшел, зәңгәр, сары, соры, очарга

**14. Әниләр бәйрәме** (7 сәгать)

булышырга, савыт-саба, үтүкләргә, сөртергә, себерергә, себерке, җыештырырга, идән, тузан, бергә, ял итәргә, кайчан, ай, көн, ел

**15. Бакчада** (7 сәгать)

бакча, чәчәк, кыяр, кишер, суган, бәрәңге, кәбестә, җиләк, җимеш, агач, төрле, үсәргә, җыярга, утарга, казырга, утыртырга, су сибәргә, чүп үләне, эшчән, ялкау

**16. Без спорт яратабыз** (7 сәгать)

ярыш, көрәш, көрәшче, чана, чаңгы, җиңү, җиңүче, җиңәргә, сикерергә, йөгерергә, катнашырга, шуарга, кышкы, җәйге, ә, тиз, әкрен (акрын)

**17. Җәйге ял** (7 сәгать)

табигать, су коенырга, кызынырга, балык тотарга, кармак, саф һава, йөрергә, җәяү, очрашырга, очратырга, күл, диңгез, Кара диңгез, быел, былтыр, гөмбә, эссе, күп, аз

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Берлек һәм күплек сандагы исемнәрне гамәли үзләштерү һәм аларга *кем?* яки *нәрсә?* сорауларын куярга өйрәтү.
2. Исемнәргә һәм зат алмашлыкларына *-ныкы/-неке* кушымчаларын ялгап, *кемнеке?* соравына җавап бирергә күнектерү.
3. Урын-вакыт, чыгыш, юнәлеш, төшем килешләрендәге исемнәрне сөйләмдә дөрес кулланырга күнектерү.
4. Исемнәрдә сан, килеш кушымчаларының ялгану тәртибен истә калдыру.
5. Баш килештәге зат һәм сорау алмашлыкларын сөйләмдә кулланырга күнектерү.
6. *Сыйфат + күплек сандагы исем (матур урамнар)* төзелмәсен дөрес кулланырга өйрәтү.
7. Микъдар һәм тәртип саннарын (1—10 саннары), *сан + исем (биш укучы)* төзелмәсен гамәли үзләштерү.
8. *Белән, турында* бәйлекләре; *күп, аз* рәвешләре белән җөмләләр төзергә өйрәтү.
9. Боерык фигыльнең II зат берлек һәм күплек сан формаларын тыңлап аңларга күнектерү.
10. Хәзерге заман хикәя фигыльләрне, барлыкта һәм юклыкта зат һәм сан белән төрләндереп, сөйләмдә куллануга ирешү.
11. *-мы/-ме, түгел* кисәкчәләрен җөмләләрдә дөрес кулланырга өйрәтү.
12. Татар җөмләсендә сүз тәртибен гамәли үзләштерү.
13. Хикәя, сорау җөмләләр төзеп әйтергә өйрәтү.

## СӨЙЛӘМ ҮРНӘКЛӘРЕ

1. Исәнмесез! (Исәнме!) Хәерле иртә! Хәерле көн! Хәерле кич! Сау булыгыз! (Сау бул!)
2. Син (ул, бу, сез, алар) кем(нәр)? Мин — Азат. Ул — укучы. Бу — әни. Алар — укучылар. Болар кемнәр? Болар — балалар.

3. Бу нәрсә? Бу — китап. Бу — песи. Болар нәрсәләр? Болар — китаплар. Болар — песиләр.

4. Бу дәфтәрме? Әйе. Бу — дәфтәр. Юк, бу дәфтәр түгел, бу — китап.

5. Азат бармы? Әйе, Азат бар. Азат юк.

6. Сыйныфта ничә укучы бар? Сыйныфта ун укучы бар.

7. Китап нинди? Китап матур. Бу нинди китап? Бу — матур китап.

8. Китап кемнеке? Китап минеке (Азатныкы, Рәшитнеке).

9. Китап кайда? Китап өстәлдә.

10. Укучы нишли? Укучы яза (сөйләшә, укый, сөйли).

11. Укучы кая бара? Ул мәктәпкә бара.

12. Укучы кайдан кайта? Ул мәктәптән кайта.

13. Бу ничәнче мәктәп? Бу — беренче мәктәп.

14. Бәйрәм кайчан була? Бәйрәм иртәгә була.

15. Ул ничек укый? Ул яхшы укый.

16. Бу китап нәрсә турында? Бу китап Казан турында.

17. Ул нәрсә турында сөйли? Ул Казан турында сөйли.

18. Ул кем белән уйный? Ул Азат белән уйный.

19. Ул мәктәптән нәрсә белән кайта? Ул трамвай белән кайта.

20. Ул нәрсә ярата? Ул алма ярата.

**ОРФОЭПИК ҺӘМ ОРФОГРАФИК МИНИМУМ**

1. Имитация һәм кабатлаулар аша авазларның сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә дөрес әйтелешен үзләштерү.

2. Татар телендәге үзенчәлекле авазларның әйтелешен истә калдыруга ирешү.

3. Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны сөйләмнең эчтәлегенә зыян китермәслек итеп әйтергә күнектерү.

4. Сүзләрнең калын яки нечкә әйтелешен гамәли үзләштерү, сингармонизм законына (рәт һәм ирен гармониясенә) буйсынган сүзләрне дөрес әйтергә күнектерү.

5. Татар һәм рус телләрендәге сузык һәм тартык авазларның әйтелешендәге аермаларны искәртү.

6. Сүзләрдә һәм аларның төрле грамматик формаларында басымны дөрес куярга өйрәтү (*-ма/-мә* юклык кушымчасы алдында; *-мы/-ме* сорау кисәкчәсе алдында; сорау алмашлыкларында).

7. Хикәя, боеру һәм сорау җөмләләрне интонацион яктан дөрес әйтергә гадәтләндерү.

8. Татар теленең иҗек калыпларына нигезләнгән уку кагыйдәләрен гамәли үзләштерү.

9. Татар хәрефләрен дөрес язарга күнектерү.

10. Сүзләрне, иҗекләргә бүлеп, юлдан-юлга күчереп язарга өйрәтү.

11. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне ишетеп язарга күнектерү.

12. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булган сүзләрнең язылышын искәртү *(төлке, борын, русча )*.

13. Ялгызлык исемнәрне баш хәрефтән язарга өйрәтү.

14. Җөмләне баш хәрефтән башлап, ахырында нокта, сорау яки өндәү билгесе куеп язарга күнектерү.

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

Укытучының дәрес үткәрү белән бәйле күрсәтмәләрен, сорауларын аңлап, сөйләшүдә катнашу;

сыйныфташларның сөйләмен ишетеп аңлау;

тыңланган сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең мәгънәсенә, аерым җөмләләрнең эчтәлегенә тулысынча төшенү.

### Диалогик сөйләм

Лексик тема буенча сорау-җавап репликаларын сөйләмдә куллану;

укытучының сорауларына җавап бирү һәм сораулар кую;

диалогларны сәнгатьле итеп уку һәм яттан сөйләү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып, сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 3 тән ким булмаска тиеш).

### Монологик сөйләм

Лексик темага караган сүзләрне кулланып, предметларны атау;

мәктәп, гаилә һәм сыйныфташларны, табигатьне тасвирлау;

укылган текстның эчтәлеген сөйләп бирү;

4 җөмләдән дә ким булмаган хикәя төзеп сөйләү.

### Уку

Телдән үзләштерелгән уку материалына бәйле җөмләләрне һәм текстларны сәнгатьле итеп уку һәм укыганның эчтәлегенә төшенү;

кечкенә шигырьләрне сәнгатьле итеп уку һәм яттан сөйләү;

халык авыз иҗаты үрнәкләрен (санамышлар, тизәйткечләр, мәкальләр) яттан әйтү.

### Язу

Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес язу;

актив үзләштерелгән сүзләрне, кыска җөмләләрне күчереп язу;

әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне дөрес язу;

җөмләне баш хәрефтән башлап, ахырында нокта, өндәү яки сорау билгесе куеп язу.

## ӘДӘБИ УКУ

Әдәби укуга өйрәтүнең төп **максатлары**:

1) гамәли үзләштергән белемнәрне әдәби әсәрләр уку аша ныгыту һәм сөйләмдә куллануга ирешү;

2) укучыларның татар телендә аралашу осталыкларын үстерү;

3) татар балалар әдәбиятының күренекле вәкилләре, аларның иҗаты турында беренчел мәгълүмат бирү;

4) әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, аңлап, сәнгатьле итеп укырга һәм уку тизлеге нормаларын үтәргә өйрәтү;

5) татар телендә укуга кызыксыну уяту, әдәби уку тәҗрибәсе булдыру һәм әдәби зәвык тәрбияләү;

6) халык әкиятләре һәм кече фольклор жанрлары белән таныштыру;

7) укучыларда әхлакый-эстетик сыйфатлар, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисләре тәрбияләү.

## ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Әдәби һәм мәгълүмати текстлар. Татар халык авыз иҗаты әсәрләре (табышмаклар, санамышлар, мәкальләр, тизәйткечләр, татар һәм рус халык әкиятләре).

Татар балалар әдәбияты әсәрләре: **Г. Тукай.** «Безнең гаилә», «Көз», «Чыршы»; **М. Җәлил.** «Яз», «Күке»; **А. Алиш.** «Әни ялга киткәч»; **З. Туфайлова.** «Туган ил»; **М. Фәйзуллина.** «Яңгыр», «Җил»; **Р. Миңнуллин.** «Песи», «Алма»; **Р. Вәлиева.** «Шаян җил»; **Л. Лерон. «Йөри торган урындык», «Радиога салкын тигән», «Кем кайда яши?».**

Рус балалар язучыларының тәрҗемә әсәрләре: **Н. Носов.** «Ямаулык»; **Л. Толстой.** «Песи баласы»; **Н. Сладков.** «Урман әлифбасы».

## 2 нче СЫЙНЫФ (204 сәгать)

АРАЛАШУ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ТЕМАЛАРЫ

1. Яңа уку елы белән!
2. Йортыбыз, фатирыбыз.
3. Көндәлек режим.
4. Ашамлыклар кибетендә.
5. Әбиләрдә кунакта.
6. Табигать.
7. Татарстан — туган җирем.
8. Казан — Татарстанның башкаласы.
9. Сәламәтлек — зур байлык.
10. Без хезмәт яратабыз.
11. Үсемлекләр белән танышабыз.
12. Хайваннарга һәм кошларга булышабыз.
13. Без бәйрәмгә барабыз.
14. Күңелле ял итәбез.

### ЛЕКСИК МИНИМУМ

**1. Яңа уку елы белән!** (15 сәгать)

белем, белергә, өйрәнергә, тыңларга, аңларга, кабатларга, сорау, сорау бирергә, җавап, җавап бирергә, тәрҗемә итәргә, мисал, күнегү, билге алырга, «биш»ле, «дүрт»ле, «өч»ле, «ике»ле, аваз, хәреф, сүз, җөмлә, өтер, нокта, тәнәфес, кирәк (түгел), ярый (ярамый)

**2. Йортыбыз, фатирыбыз** (15 сәгать)

бүлмә, алгы бүлмә, аш бүлмәсе, кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе, юыну бүлмәсе, ишек, ачкыч, тәрәзә, тәрәзә төбе, гөл, сәгать, идән, түшәм, җиһаз, өстәл, журнал өстәле, язу өстәле, урындык, кәнәфи, элгеч, карават, киштә, суыткыч, кием шкафы, савыт-саба шкафы, келәм, якты, чиста

**3. Көндәлек режим** (15 сәгать)

дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе, кичә, бүген, иртәгә, иртән, кичен, көндез, башта, аннары, тагын, торырга, йокларга ятарга, юынырга, сөртенергә, киенергә, дәрес әзерләргә, сөлге

**4. Ашамлыклар кибетендә** (15 сәгать)

ашамлык, балык, каймак, эремчек, сөт, он, ит, тоз, хәлвә, шикәр комы, җиләк-җимеш, перәнник, туңдырма, тартма, акча, сум, тиен (копейка), сайларга, түләргә, үлчәргә

**5. Әбиләрдә кунакта** (15 сәгать)

кунак, чакырырга, күчтәнәч, табын, ашъяулык, кулъяулык, токмачлы аш, шулпа, ботка, сыйларга, салырга, бәхетле, шатлыклы, тәрбияле, рәхмәт әйтергә, әле, бик

**6. Табигать** (15 сәгать)

табигать, кышын, язын, көзен, җәен, кышкы, язгы, җәйге, көзге, боз каплый, тамчы тама, кар эри, гөрләвек ага, яшен яшьни, күк күкри, салават күпере чыга, көн кыскара, төн озыная, соң (после), пычрак, бераз

**7. Татарстан — туган җирем** (15 сәгать)

җир, туган, халык, Алабуга, Чистай, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә, Нократ, Идел, Казансу, Агыйдел, урнашкан, елга ага, аша (аркылы), өчен, кадәр, күл, буенда, чишмә, дала, төзергә, төзелеш, мәчет, чиркәү, тимер юл, бай

**8. Казан — Татарстанның башкаласы** (15 сәгать)

башкала, бина, манара, үзәк, кунакханә, ашханә, даруханә, истәлекле урын, сарай (дворец), тукталыш, иске, яңа, ерак, якын, туктарга, анда, монда, таныш, тапкыр (раз), алда, артта

**9. Сәламәтлек — зур байлык** (14 сәгать)

сәламәт, сәламәтлек, байлык, авырый, авырта, йөткерә, йөрәк, эч, табиб(ә), хастаханә, дәваларга, ятарга, шөгыльләнергә, ишетергә, күрергә, сирәк, еш

**10. Без хезмәт яратабыз** (14 сәгать)

тырыш, ялкау, ярдәмчел, хезмәт, ташырга, ташларга, чүп, чиләк, чүпрәк, ябарга, ачарга, чыгарга, кирәкергә, яме, һәрвакыт, кайвакыт, үзе

**11. Үсемлекләр белән танышабыз** (14 сәгать)

үсемлек, үлән, ботак, яфрак, имән, каен, нарат, алмагач, шомырт, миләш, балан, карлыган, кура җиләге, җир җиләге, чия

**12. Хайваннарга һәм кошларга булышабыз** (14 сәгать)

җим, җимлек, ясарга, файда китерә, зыян китерә, өн, оя, күсе, тычкан, көньяк, төньяк, кышларга, тышта, ашатырга

**13. Без бәйрәмгә барабыз** (14 сәгать)

тамаша, тамашачы, сәхнә, чыгыш, баянчы, кул чабарга, яраткан, Җиңү бәйрәме, Яз һәм Хезмәт бәйрәме, Сабантуй, көрәш, ат чабышы, аркан тартышу, шома баганага менү, чүлмәк вату, капчык белән сугышу

**14. Күңелле ял итәбез** (14 сәгать)

күңелле, ял, ял итәргә, ямьле, күтәргә, каршыларга, сагынырга, озатырга, үткәрергә, йөзәргә, әбәкле уйнарга, качышлы уйнарга, таган атынырга, ком, кәрзин, тулы, буш, күбәләк оча, кошлар сайрый

### ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Исемнәрнең сан һәм килеш белән төрләнешен кабатлау.
2. Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнешен гамәли үзләштерү.
3. *Иялек килешендәге исем + тартымлы исем (укучының дәфтәре)* төзелмәсен сөйләмдә кулланырга өйрәтү.
4. Лексик темаларга караган сыйфатларны сөйләмгә кертү.
5. Зат алмашлыкларын, килеш белән төрләндереп, сөйләмдә кулланырга күнектерү.
6. Лексик темага караган хәзерге заман хикәя фигыльләрне сөйләмдә дөрес куллануга ирешү.
7. Билгеле үткән заман хикәя фигыльне, барлыкта һәм юклыкта затсан белән төрләндереп, сөйләмдә кулланырга күнектерү.
8. Өйрәнелгән кисәкчәләрне кабатлау; *бик, әле, тагын* кисәкчәләрен гамәли үзләштерү.
9. Үзләштерелгән бәйлекләрне кабатлау; *өчен, кадәр, соң* бәйлекләрен сөйләмдә дөрес куллануга ирешү.
10. Боерык фигыльнең II зат берлек һәм күплек сан формаларын кабатлау.
11. Үзләштерелгән саннарны кабатлау; *егерме, утыз, кырык, илле, алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан, йөз* микъдар саннарын һәм җыю *(дүртәү, унау)* саннарын кулланылышка кертү.
12. *Кирәк (түгел), мөмкин (түгел), ярый, ярамый, кирәк (кирәк түгел)* сүзләрен фигыльнең инфинитив формасы белән кулланырга өйрәтү.
13. Җөмләнең коммуникатив төрләрен (раслау, инкяр, сорау, хикәя, боеру) диалогик һәм монологик сөйләмдә дөрес кулланырга күнектерү.
14. Өйрәнелгән җөмлә калыпларын җәенкеләндереп әйтергә өйрәтү.
15. *Һәм, ә* теркәгечләрен сөйләмгә кертү.

### СӨЙЛӘМ ҮРНӘКЛӘРЕ

1. Керергә (чыгарга ) ярыймы? Әйе, ярый. Юк, ярамый.
2. Гафу итегез, сүзлекне алырга ярыймы? Әйе, ярый, рәхим ит.
3. Кунакка килегез! Хуш килдегез! Күчтәнәчегез өчен рәхмәт!
4. Китабың бармы? Әйе, китабым бар.
5. Китап кирәкме? Әйе, китап кирәк. Юк, китап кирәк түгел.
6. Бу кемнең китабы (дәфтәре, апасы, энисе)? Бу Азатның (Әлфиянең) китабы (дәфтәре, апасы, энисе).
7. Сиңа ничә яшь? Миңа 8 яшь.
8. Бүген ничә дәресегез бар? Өч дәресебез бар.
9. Язарга мөмкинме? Әйе, мөмкин.

10. Бу китапны укырга кирәкме? Әйе, бу китапны укырга кирәк.
11. Бу китап кемнәр өчен? Бу китап балалар өчен.
12. Ул кая барды (бармады)? Ул мәктәпкә барды (бармады).
13. Мин укыйм һәм язам. Мин укыйм, ә ул яза.
14. Марат, укы! Балалар, укыгыз!
15. Сез ничәү? Без дүртәү.
16. Яздан соң җәй килә.
17. Кичкә кадәр кар яуды.

### ОРФОЭПИК ҺӘМ ОРФОГРАФИК МИНИМУМ

1. Татар алфавитын яттан әйтергә өйрәтү.
2. Татар хәрефләре белдергән авазларның әйтелешен ныгыту.
3. Лексик темаларга караган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрне аера белергә күнектерү.
4. Нечкәлек яки калынлык билгесе булган гади сүзләрне *(сәгать, шигырь),* кушма сүзләрне *(көньяк, кульяулык)* дөрес әйтергә күнектерү.
5. [къ], [гъ], [ж], [ң], [һ], [ч], [’] (һәмзә) авазы булган сүзләрнең әйтелешен гамәли үзләштерүгә ирешү.
6. Тыңланган яки укылган сүзләрне иҗекләргә бүлеп әйтү күнекмәләре булдыру.
7. Татар сөйләмен интонацион яктан дөрес оештырырга өйрәтү.
8. Сүзләрне үзгәрешсез күчереп язарга күнектерү.
9. Орфографик күнекмәләрне камилләштерү.

### СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

#### Тыңлап аңлау

Укытучының яки башка укучыларның сөйләмен ишетеп аңлау;

0,5—1 минутлык текстны тыңлап аңлау һәм, төп эчтәлегенә төшенеп, укытучының сорауларына җавап бирү;

текстны тыңлау һәм бирелгән җөмләләр арасында эчтәлегенә туры килгәннәрен билгеләү.

#### Диалогик сөйләм

Лексик тема буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 4 тән ким булмаска тиеш);

укылган яки тыңланган текстның төп эчтәлеге буенча әңгәмә кору;

бирелгән үрнәк буенча охшаш диалог төзеп сөйләү.

#### Монологик сөйләм

Бирелгән ситуация, лексик тема яки сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя төзеп сөйләү (җөмләләр саны 5 тән ким булмаска тиеш);

укылган яки тыңланган текстның төп эчтәлеген сөйләп бирү.

#### Уку

Текстларны сәнгатьле итеп уку һәм укыганның эчтәлегенә тулысынча төшенү;

текsттагы яңа сүзләрнең мәгънәләрен контексттан чыгып аңлау яки сүзлектән табу;

текстны эчтән уку һәм эчтәлеген сөйләү;

шигырьләрне яттан сөйләү.

**Язу**

Хәрефләрне һәм сүзләрне дөрес язу;

аерым җөмләләрне, кечкенә текстларны үзгәрешсез күчереп язу;

әйтелеше белән языльшы арасында аерма булмаган сүзләрдән торган диктант язу;

бирелгән үрнәк буенча котлау язу.

## ӘДӘБИ УКУ

Әдәби укуга өйрәтүнең төп **максатлары**:

1) гамәли үзләштергән белемнәрне әдәби әсәрләр уку аша ныгыту һәм сөйләмдә куллануга ирешү;

2) укучыларның татар телендә аралашу осталыкларын үстерү;

3) татар балалар әдәбиятының күренекле вәкилләре, аларның иҗаты турында мәгълүмат бирү;

4) әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, аңлап, сәнгатьле итеп укырга һәм уку тизлеге нормаларын үтәргә өйрәтү;

5) татар телендә укуга кызыксыну уяту, әдәби уку тәҗрибәсен үстерү һәм әдәби зәвык тәрбияләү;

6) әдәби әсәрдәге төп тема, вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;

7) автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәсәлләрне әдәби жанр буларак кабул итәргә күнектерү.

8) укучыларда әхлакый-эстетик сыйфатлар, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисләре тәрбияләү.

## ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Әдәби һәм фәнни-популяр текстлар. Татар халык авыз иҗаты әсәрләре (табышмаклар, санамышлар, мәкальләр, тизәйткечләр, татар һәм рус халык әкиятләре).

Татар балалар әдәбиятының күренекле язучылары әсәрләре: **Г. Тукай.** «Кызыклы шәкерт», «Кышкы кич», «Иртә»; **А. Алиш.** «Алдакчы Наил»; **Б. Рәхмәт.** «Әсма мәктәпкә бара», «Кыш килде», «Урамда йөрү»; **Ә. Бикчәнтәева.** «Мәктәпкә», «Дәү әнием»; **М. Фәйзуллина.** «Миләүшә», «Энҗе чәчәк»; **Ш. Галиев.** «Шәвәли сәгате», «Яз», «Чабалар»; **Р. Миңнуллин.** «Әни», «Мактанырга яратмый»; **Р. Вәлиева.** «Сарбай белән ишек», «Дәү әни», «Укый беләм»; **З. Туфайлова.** «Әни сүзе».

Рус балалар язучыларының тәрҗемә әсәрләре: **Н. Носов.** «Шалкан турында»; **А. Гайдар.** «Күңел газабы»; **Л. Толстой.** «Ике ат».

# 3 нче СЫЙНЫФ (170 сәгать)

АРАЛАШУ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ТЕМАЛАРЫ

1. Белем бәйрәме.
2. Сәламәт булыгыз!
3. Спорт уеннары.
4. Ашханәдә.
5. Базарда.
6. Без театрга барабыз.
7. Бәйрәмнәр.
8. Һөнәрләр белән танышабыз.
9. Татарстан — безнең Ватаныбыз.
10. Әти-әниләргә булышабыз.
11. Без сәяхәткә чыгабыз.

**ЛЕКСИК МИНИМУМ**

**1. Белем бәйрәме** (16 сәгать)

дәрес, дәреслек, сүзлек, көндәлек, бетергеч, сызгыч, уку, язу, хата, дөрес, рәсем, рәсем ясарга, буяу, җилем (клей), өй эше, бирем, эш дәфтәре, кайчы, кәгазь, төсле кәгазь, карандаш очлагыч

**2. Сәламәт булыгыз!** (16 сәгать)

сәламәт, дару, даруханә, дәваланырга, терелергә, сызларга, тамак, салкын тияргә, чыныгырга, онытырга, таза, ябык, симез, файдалы, дару үләннәре, мәтрүшкә, гөлҗимеш, кычыткан

**3. Спорт уеннары** (16 сәгать)

кышын, җәен, уен, кызыклы, кәшәкә, тимераяк, шугалак, тау, шуарга, шаярырга, шаян, рәхәт, дуслык, оста, шахматчы, буенча, беренчелек

**4. Ашханәдә** (16 сәгать)

аш, ашханә, иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш, кәбестә ашы, токмачлы аш, пылау, пилмән, ботка, дөге, солы, карабодай, тавык ите, алма пирогы, йомырка, кесәл, ач, тук, әдәпле

**5. Базарда** (16 сәгать)

кавын, карбыз, әфлисун, чикләвек, өрек, йөзем, борыч, сарымсак, чөгендер, шалкан, кабак, чәчәк бәйләме, роза чәчәге, лалә, энҗе чәчәк, ак чәчәк

**6. Без театрга барабыз** (15 сәгать)

тамаша, тамаша залы, тамашачы, көй, башкаручы, башкарырга, ошарга, оста, осталык, сәхнә, пәрдә ачыла, ябыла, рәхмәтле булырга

**7. Бәйрәмнәр** (15 сәгать)

тантана, кичә (вечер), халыкара, милли, дини, Нәүрүз бәйрәме, карга боткасы, бәйрәм итәргә, табышмак, башваткыч, тизәйткеч, берничә, үткәрергә

**8. Һөнәрләр белән танышабыз** (15 сәгать)

һөнәр, танышырга, төзүче, тегүче, балыкчы, рәссам, язучы, шагыйрь, шигырь, тәрбияче, китапханәче, пешекче, нефтьче, машина йөртүче, хат ташучы, урманчы, эшләргә, булып

**9. Татарстан — безнең Ватаныбыз** (15 сәгать)

ватан, тарих, дәүләт, ил башлыгы, көнчыгыш, көнбатыш, көньяк, төньяк, күрше, халык, күпчелек, авыл хуҗалыгы, чикләшергә, бәйләнеш, тыгыз, чит, җитештерергә, кара алтын табыла, горурланырга

**10. Әти-әниләргә булышабыз** (15 сәгать)

хуҗа, хуҗабикә, хуҗалык, булышырга, кер юу машинасы, тегү машинасы, тегәргә, бәйләргә, чигәргә, пычак, чүкеч, кисәргә, кадак кагарга, такта, пычкы, балта, утын ярырга

**11. Без сәяхәткә чыгабыз** (15 сәгать)

сәяхәт, сәяхәт итәргә, сәяхәтче, юлдаш, башка (другой), чит ил, җыенырга, саен, һәр, диңгез, тау башында, күл буенда, күл төбендә, урман буйлап, чишмә, җәяү, учак ягарга, иң, теге

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Сан, тартым, килеш белән төрләнгән исемнәрне сөйләмдә куллану күнекмәләрен ныгыту.
2. Килеш белән төрләнгән зат алмашлыкларын, күрсәтү, сорау, тартым алмашлыкларын сөйләмдә дөрес куллануга ирешү.
3. Тезмә (*җир җиләге*), кушма (*көнбатыш*), парлы (*әти-әни*) исемнәрнең мәгънәсенә төшендерү.
4. Лексик темаларга караган сыйфатларны чагыштыру дәрәҗәсендә кулланырга өйрәтү.
5. Хәзерге һәм билгеле үткән заман хикәя фигыльләрне, барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләндереп, сөйләмдә куллану күнекмәләрен ныгыту.
6. Билгесез үткән заман хикәя фигыльләрнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнешен гамәли үзләштерү.
7. *Алдында, артында, өстендә, астында, янында* бәйлек сүзләре белән җөмләләр төзергә күнектерү.
8. *Ләкин, чөнки* теркәгечле җөмләләрне аңларга өйрәтү. Аларда басымның беренче иҗеккә төшүен искәртү.

9. *Әле, инде* кисәкчәләре белән җөмләләр төзергә күнектерү.

10. *Кебек (шикелле), аркылы, саен, бирле* бәйлекләрен исемнәр һәм алмашлыклар белән кулланырга өйрәтү.

11. Раслау, инкяр, сорау, боеру җөмләләрне диалогик һәм монологик сөйләмдә куллану күнекмәләрен камилләштерү.

**СӨЙЛӘМ ҮРНӘКЛӘРЕ**

1. Ашыгыз тәмле булсын! Бергә булсын!
2. Дәфтәрләрегез кайда? Дәфтәрләребез өстәлдә.
3. Кызның апалары кайда яши? Аның апалары авылда яши.
4. Татарстанда иң зур шәһәр — Казан.
5. Бу китап бик кызыклы.
6. Мин бу биремне язмадым әле. Ул бу җөмләне укыды инде.
7. Ул әтисе кебек тырыш.
8. Ул юл аркылы чыга.
9. Яздан бирле яңгыр юк.
10. Ул ел саен авылга кайта.
11. Китап өстәл өстендә (астында, алдында, артында).
12. Бүген салкын, чөнки җил бар.
13. Бүген җылы, ләкин яңгырлы көн.
14. Бу китап матур, ә теге китап матуррак.
15. Бу шагыйрь балалар өчен шигырьләр язган.

**ОРФОЭПИК ҺӘМ ОРФОГРАФИК МИНИМУМ**

1. Авазларны, лексик темаларга караган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтергә күнектерү.

2. Басым беренче иҗеккә төшкән сүзләрне дөрес әйтүгә ирешү.

3. Алынма сүзләрнең әйтелешен истә калдыру.

4. Янәшә килгән ике тартык булган сүзләрнең әйтелешен һәм аваз үзгәрешләрен искәртү *(исә**нм**есез, у**нб**ер, бо**рын**гы)*.

5. Янәшә килгән ике бертөрле тартык булган сүзләрне дөрес әйтү күнекмәләре булдыру *(а**кк**ош, э**сс**е, ки**тт**е* һ. б.).

6. [р] авазына башланган сүзләрнең әйтелешен гамәли үзләштерү [‘рәсэм], [ырам].

7. *Я, ю, е* хәрефләре белдергән авазларны гамәли үзләштерү (*яшел*- [йәшэл]; *яңа* — [йа°ңа], *юл* — [йул]; *егет* — [йэгэт]; *ел* — [йыл]).

8. Орфографик күнекмәләрне камилләштерү.

**СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР**

**Тыңлап аңлау**

Укытучының күрсәтмәләрен бер әйтүдән тулысынча аңлап бару;

дәрес барышында җанлы сөйләмне тыңлап һәм төшенеп бару;

1—1,5 минутлык текстны тыңлап, аның төп эчтәлеген сөйләп бирү.

**Диалогик сөйләм**

Лексик тема буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 5 тән ким булмаска тиеш);

сорау яки җавап репликаларын өстәп, диалог төзеп сөйләү;

укылган яки тыңланган текстның төп эчтәлеге буенча сораулар кую һәм җавап бирү.

**Монологик сөйләм**

Укытучы тәкъдим иткән ситуация яки рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү (җөмләләр саны 6 дан ким булмаска тиеш);

хикәянең ахырын уйлап бетерү һәм сөйләү;

укылган яки тыңланган текстның төп эчтәлеген сөйләп бирү.

**Уку**

Әдәби текстларны эчтән яки кычкырып уку һәм төп эчтәлегенә төшенү;

укылган тексттагы таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен аңлау;

татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен (мәкальләр, санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар) яттан әйтү;

шигырьләрне яттан сөйләү.

**Язу**

Актив үзләштерелгән сүзләрне яттан язу;

лексик тема яки сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя язу;

укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;

бәйрәм белән котлау язу.

## ӘДӘБИ УКУ

Әдәби укуга өйрәтүнең төп **максатлары**:

1) гамәли үзләштергән белемнәрне әдәби әсәрләр уку аша ныгыту һәм сөйләмдә куллануга ирешү;

2) укучыларның татар телендә аралашу осталыкларын камилләштерү;

3) татар балалар әдәбиятының күренекле вәкилләре, аларның иҗаты турында мәгълүматларны киңәйтү;

4) әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, аңлап, сәнгатьле итеп укырга өйрәтү;

5) татар телендә укуга кызыксыну уяту, әдәби уку тәҗрибәсен үстерү һәм әдәби зәвык тәрбияләү;

6) әсәрнең төп герое характерын, гамәлләрен һәм гамәл кылырга этәргән сәбәпләрне, геройның эмоциональ һәм әхлакый кичерешләрен аңлап, геройга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;

7) халык әкиятләрен һәм кече фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәсәлләрне әдәби жанр буларак кабул итү күнекмәсен үстерү;

8) укучыларда әхлакый-эстетик сыйфатлар, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисләре тәрбияләү.

## ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Әдәби һәм фәнни-популяр текстлар. Татар халык авыз иҗаты әсәрләре (табышмаклар, санамышлар, мәкальләр, тизәйткечләр, татар һәм рус халык әкиятләре).

Татар балалар әдәбиятының күренекле язучылары әсәрләре: **Г. Тукай.** «Кырлар буш кала», «Җир йокысы», «Кояш», «Бала белән күбәләк»; **М. Җәлил.** «Көз җитте», «Күке»; **А. Алиш.** «Чукмар белән Тукмар»; **Б. Рәхмәт.** «Аш вакыты», «Кошлар киткәндә», «Китаплар»; **Ә. Бикчәнтәева.** «Әтием белән бергә», «Карлар ява», «Колын»; **Җ. Тәрҗеманов.** «Кояш чыкты»; **З. Туфайлова.** «Туган ил»; **М. Фәйзуллина.** «Гөлнар мәктәпкә бара»; **Д. Аппакова.** «Тагын урамга», «Март башы»; **Ш. Галиев.** «Рус казлары: га-га-га», «Рәхмәт»; **Р. Миңнуллин.** «Гаҗәп кунак», «Үзем белән үзем», «Сабантуй бүген бездә»; **Р. Вәлиева.** «Иң матур җир», «Туган көндә».

Рус балалар язучыларының тәрҗемә әсәрләре: **Н. Носов.** «Эшләпә»; **Л. Толстой.** «Көймә».

# 4 нче СЫЙНЫФ (170 сәгать)

АРАЛАШУ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ТЕМАЛАРЫ

1. Мәктәптә.
2. Татарстан Республикасының дәүләт символлары.
3. Татарстанның тарихы белән танышабыз.
4. Табигатьне саклыйбыз.
5. Музейларга барабыз.
6. Үзәк универмагта.
7. Һөнәрләр.
8. Зоопаркта.
9. Исәнме, җәй!
10. Балачак китапларым.

**ЛЕКСИК МИНИМУМ**

**1. Мәктәптә** (17 сәгать)

акыллы, тапкыр, сәләтле, белемле, сабыр, уйларга, тикшерергә, санарга, кушарга, алырга (отнять), бүләргә, тапкырларга, чишәргә, мәсьәлә, чагыштырырга

**2. Татарстанның дәүләт символлары** (17 сәгать)

Дәүләт гербы, дәүләт флагы, дәүләт гимны, дәүләт теле, барлык (бөтен), тасма, намус, тынычлык, көч, халык, матурлык, канатлы, ак барс, боҗра, калкан, кашкарый, җилфердәргә, яңгырарга, хөрмәт итәргә

**3. Татарстанның тарихы белән танышабыз** (17 сәгать)

Болгар дәүләте, Казан ханлыгы, тарих, тарихи, хәтер, хәтерләргә, галим, ачыш, казаныш, үсеш алырга, Казан Кремле, Кол Шәриф мәчете, Благовещение соборы, Сөембикә манарасы, Спасс манарасы

**4. Табигатьне саклыйбыз** (17 сәгать)

Кызыл китап, сакларга, яхшыртырга, байлык, пычратырга, өзәргә, таптарга, агулы, зарарлы, саф һавалы, каршы, әллә, икән, йөрергә, шатланырга

**5. Музейларга барабыз** (17 сәгать)

күргәзмә, сынлы сәнгать, милли, сакланырга, корал, шәхси әйберләр, таш, мәрмәр, алтын, көмеш, сын, сынчы, гасыр, борынгы

**6. Үзәк универмагта** (17 сәгать)

үзәк, бүлек, сатып алырга, сатарга, өй җиһазлары, бизәнү әйберләре, баш киемнәре, өс киемнәре, аяк киемнәре, алка, йөзек, муенса, беләзек, киеп карарга, килешергә (быть к лицу), игътибар, игътибарлы, ачык, ябык

**7. Һөнәрләр** (17 сәгать)

оешма, җитәкче, эш, эшче, эшкуар, рәис, урынбасар, ярдәмче, тәрҗемәче, нефтьче, хисапчы, мактарга, ихтирам итәргә, тиеш

**8. Зоопаркта** (17 сәгать)

дөя, фил, арыслан, юлбарыс, көнгерә, ишәк, бака, ташбака, маймыл, су үгезе, елан, ишәк, ләкләк, лачын, торна, бөркет, ябалак, тукран, аккош, акчарлак, шуышырга, читлек

**9. Исәнме, җәй!** (17 сәгать)

озакламый, күптән (түгел), яңадан, әлбәттә, бигрәк тә, ашыгырга, күңел ачарга, аралашырга, кызыксынырга, мавыгырга, рәхәтләнеп, бирегә (монда), тегендә (анда)

**10. Балачак китапларым** (17 сәгать)

сөйләргә, кызыксынырга, яратып укырга, халык әкияте, тылсымлы әкият, балалар әдәбияты, мавыктыргыч, мәкаль, санамыш, табышмак, тизәйткеч, батырлык, дуслык, тырышлык, намуслылык, тынычлык, куркаклык, явызлык, наданлык, көләргә, еларга

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Берлек һәм күплек сандагы уртаклык һәм ялгызлык исемнәрне, сан, тартым һәм килеш белән төрләндереп, сөйләмдә куллану күнекмәләрен үстерү.
2. Актив үзләштерелгән сыйфатларны төп, чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләрендә куллануга ирешү.
3. Хикәя фигыльнең өйрәнелгән заман формаларын аера белергә һәм гамәли кулланырга күнектерү.
4. *Гына/генә, кына/кенә* кисәкчәләре белән җөмләләр төзергә өйрәтү.
5. Күрсәтү алмашлыкларының *(бу, теге)* килеш формаларын, *әнә, менә* алмашлыкларын дөрес куллануга ирешү.
6. *Таба, соң, кадәр* бәйлекләрен сөйләмгә кертү.
7. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльне, барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләндереп, сөйләмдә кулланырга өйрәтү.
8. Татар һәм рус җөмләләрендә сүз тәртибе үзенчәлекләрен искәртү.
9. Грамматик белемнәрне гомумиләштерү нигезендә укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерү.

## СӨЙЛӘМ ҮРНӘКЛӘРЕ

1. Хәлләр ничек? Рәхмәт, яхшы.
2. Иртәгәгә кадәр! Кичкә кадәр!
3. Җәен ул кая барачак (бармаячак)? Ул авылга кайтачак (кайтмаячак).
4. Анда нәрсә бар? Анда сүзлек бар. Монда кемнәр бар? Монда балалар бар.
5. Әнә универмаг. Менә зоопарк.
6. Әнә анда кем бар? Анда бер кеше бар.
7. Ул вокзалга таба бара.
8. Яздан соң җәй килә.
9. Без сәгать икегә кадәр укыйбыз. Без театрга кадәр җәяү бардык.
10. Бүген сезгә кемнәр килә? Бүген безгә **кунаклар** килә. Кунаклар бүген кемнәргә килә? Кунаклар бүген **безгә** килә. Кунаклар сезгә кайчан килә? Кунаклар безгә **бүген** килә.

## ОРФОЭПИК ҺӘМ ОРФОГРАФИК МИНИМУМ

1. Лексик темаларга караган сүзләрне дөрес әйтүгә ирешү.
2. Сингармонизм законының асылын гамәли үзләштерү.
3. Сүзләрне, аерым җөмләләрне үзгәрешләр кертеп язуга ирешү.
4. Исемнәрнең — сан, тартым, килеш кушымчаларын, фигыльләрнең барлык-юклык, зат-сан, заман кушымчаларын дөрес язарга өйрәтү.
5. Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп язарга күнектерү.
6. Кеше исемнәрен һәм фамилияләрен, шәһәр, авыл һәм елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәрефтән язарга күнектерү.
7. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булган сүзләрне дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен системалаштыру.
8. Сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештыруга ирешү.

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

Авазларны тыңлап, аларны белдергән хәрефләрне күрсәтү;

укытучы әйткән сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итү;

1,5—2 минутлык текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сөйләшү;

дәрестә катнашучыларның җанлы сөйләмен тыңлап, эчтәлегенә төшенү.

### Диалогик сөйләм

Сорау һәм җавап репликаларын кулланып, көндәлек тормыш белән бәйле ситуацияләргә диалог төзеп сөйләү (һәр укучының репликалар саны 6 дан ким булмаска тиеш);

танышу, исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү, котлау сүзләрен, сөйләм этикеты үрнәкләрен урынлы куллану;

укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча сөйләшү үткәрү.

### Монологик сөйләм

Тасвирлау һәм хикәяләү элементларын кертеп, лексик тема буенча эзлекле сөйләм оештыру (җөмләләр саны 7 дән ким булмаска тиеш);

укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләгәндә, төрле җөмлә калыпларын урынлы куллану һәм фикерне эзлекле белдерү.

### Уку

Хикәяләү һәм тасвирлау элементларын үз эченә алган әдәби текстларны сәнгатьле итеп уку;

тексттагы яңа сүзләрнең мәгънәләрен контексттан чыгып аңлату;

татар балалар язучылары әсәрләреннән алынган өзекләрне укып, эчтәлеген сөйләү;

шигырьләрне яттан сөйләү.

### Язу

Гаилә-көнкүреш һәм уку хезмәтенә бәйле темаларга яки сюжетлы рәсемнәр буенча кечкенә сочинение язу;

тыңланган яки укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;

аерым сүзләрне, җөмләләрне, бәйләнешле текстларны үзгәрешләр кертеп язу.

## ӘДӘБИ УКУ

Әдәби укуга өйрәтүнең төп **максатлары**:

1) гамәли үзләштергән белемнәрне әдәби әсәрләр уку аша ныгыту һәм сөйләмдә куллануга ирешү;

2) укучыларның татар телендә аралашу осталыкларын үстерү;

3) татар балалар әдәбиятының күренекле вәкилләре, аларның иҗаты турында өстәмә мәгълүмат бирү;

4) әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, аңлап, сәнгатьле итеп укуны камилләштерү һәм уку тизлеге нормаларын үтәргә өйрәтү;

5) татар телендә укуга кызыксыну уяту, әдәби уку тәҗрибәсен үстерү һәм әдәби зәвык тәрбияләү;

6) әсәрнең темасы һәм төп геройның характерын, гамәлләре һәм гамәл кылырга этәргән сәбәпләрне, геройның эмоциональ һәм әхлакый кичерешләрен аңларга һәм әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;

7) халык әкиятләрен һәм кече фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәсәлләрне әдәби жанр буларак танырга өйрәтү;

8) укучыларда әхлакый-эстетик сыйфатлар, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисләре тәрбияләү.

## ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Әдәби һәм фәнни-популяр текстлар. Татар халык авыз иҗаты әсәрләре (табышмаклар, санамышлар, мәкальләр, тизәйткечләр, татар һәм рус халык әкиятләре).

Татар балалар әдәбиятының күренекле язучылары әсәрләре: **Г. Тукай.** «Кызыклы шәкерт», «Яңгыр», «Туган тел», «Умарта корты һәм чебеннәр», «Һава», «Су»; **М. Җәлил.** «Бакчачы»; **А. Алиш.** «Нечкәбил»; **Б. Рәхмәт.** «Иң күңелле чак», «Ашаганда»; **Ә. Бикчәнтәева.** «Апрель»; **Җ. Тәрҗеманов.** «Җепшек көндә», «Кыш бабай»; **М. Фәйзуллина.** «Маяк», «Чисталык яратабыз», «Ял итми калам»; **Д. Аппакова.** «Шыгырдавыклы башмаклар»; **Ш. Галиев.** «Буш вакыт», «Авылча, бабайча ял», «Шөпшә», «Түү-түү-түү-түт»; **Р. Миңнуллин.** «Җәйне озатканда», «Отличник», «Авырып ятканда»; **Р. Вәлиева.** «Туган көндә», «Сөбханалла!»

Рус балалар язучыларының тәрҗемә әсәрләре**: М. Пришвин.** «Кеш»; **А. Гайдар.** «Чук һәм Гек»; **Л. Толстой.** «Алмагачлар».

Балалар әдәбиятының дөньякүләм танылган классиклары тәрҗемә әсәрләре: **Ш. Перро.** «Көлкәй»; **Я. Гримм, В. Гримм.** «Күңелле музыкантлар».

Төрле энциклопедияләр материаллары, белешмәлек-сүзлекләр материаллары һәм балалар өчен басылган вакытлы матбугат мәгълүматлары.

# ТӨП ҺӘМ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕ (5—11 нче СЫЙНЫФЛАР)

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Төп белем бирү һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен камилләштерү белән беррәттән, татар дөньясы, мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында күпкырлы мәгълүмат бирү, ягъни укучыларның **коммуникатив компетенцияләрен** үстерүне дәвам итү гомуми максат итеп билгеләнә. Моңа ирешү өчен, татар сөйләмен фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү; сөйләмне тыңлап аңлау күнекмәләрен тирәнәйтү; бирелгән ситуация буенча диалогик яки монологик сөйләм булдыруга ирешү; карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләреннән файдаланып, төрле жанрлардагы текстларны аңлап уку һәм текстта күтәрелгән проблемаларны төгәл билгеләргә һәм аларга карата үз мөнәсәбәтеңне белдерергә өйрәтү; татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре һәм әдипләре белән таныштыру юнәлешендә эзлекле эш алып бару зарур. Төп гомуми белем бирү һәм урта гомуми белем бирү мәктәбендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә (сөйләү, тыңлап аңлау, уку, язу) үзара бәйләнештә өйрәтү төп максатларның берсе булып тора. Укучыларда аралашу барышында куелган коммуникатив максатларга ирешү; укылган (тыңланган) текстларның эчтәлеген эзлекле итеп сөйли алу һәм телдән белдерелгән фикерләрне язмача оештыра алу күнекмәләре булдыру иң мөһим эшләрдән саналырга тиеш.

Татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп принциплары, методлары, эчтәлеге башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе программасында төгәл билгеләнгән. Төп белем бирү һәм урта белем бирү мәктәбендә дә укытучы, аңлы-коммуникатив методка нигезләнеп, телгә өйрәтүне гамәли эшчәнлеккә юнәлтергә тиеш.

Укучыларның фонетик күнекмәләрен тирәнәйтү өчен, сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештырырга күнектерү мөһим. Мондый күнекмәләргә ия булганда гына, укучылар татар телендә аралашу барышында үз фикерләрен төгәл белдерә алалар. Укучыларның лексик күнекмәләрен үстерү өчен, сүзләрнең мәгънәсен, башка сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә куллану үзенчәлекләрен гамәли үзләштерүгә игътибарны арттыру зарур. Моның белән беррәттән, татар һәм рус сүзләренең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару да *(пешерергә — варить, готовить, печь; юарга — стирать, мыть*), рус телендә эквивалентлары булмаган сүзләрне *(каз өмәсе, карга боткасы)* аңлатып бирү дә, сүзләрнең антонимнары һәм синонимнары белән таныштыру һәм аларны сөйләмдә кулланырга өйрәтү дә әһәмияткә ия.

Татар телендә күпмәгънәлелек күренешенең аеруча киң таралуын истә тотып, укытучы сүзнең тиешле мәгънәсен контексттан чыгып аңларга өйрәтүгә аерым игътибар бирергә тиеш. Болай эшләү укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, телдән һәм язма сөйләмне дөрес оештыру өчен нигез булып тора. Укучыларның грамматик күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү төрле сүз төркемнәренең морфологик формаларын, җөмлә калыпларын, тотрыклы сөйләм гыйбарәләрен гамәли үзләштерү һәм аларны сөйләмдә кулланырга күнектерүдән гыйбарәт. Рус телле балаларга, татар телен укытканда, лексик-грамматик материалны синтаксик нигездә үзләштерү принцибына таянып эш итү кирәк, чөнки, сүзләр башка сүзләр белән бәйләнештә булганда гына, сөйләм барлыкка килә. Димәк, мондый күнекмәләр җөмләнең, диалогик яки монологик хәбәрләмәнең, бәйләнешле текстның грамматик дөреслеген һәм төгәллеген тәэмин итәргә тиешләр. Укучыларның ана теле үзенчәлекләрен исәпкә алу принцибы да укытучы игътибарыннан читтә калмаска тиеш, чөнки татар һәм рус җөмләләрендә сүзләрне үзара бәйләү закончалыклары күпкә аерыла, ә бу исә укучылар сөйләмендә интерферент хаталарга китерә.

Урта гомуми белем бирү мәктәбендә (10—11 нче сыйныфлар) укытучы төп игътибарны укучыларның лексик-грамматик белемнәрен гомумиләштерүгә һәм системалаштыруга, телдән һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә, фикер йөртү сәләтен үстерүгә, аларда мөстәкыйльлек, иҗади активлык, әхлаклылык тәрбияләүгә юнәлтергә тиеш. Санап чыккан бурычларны уңышлы хәл иткәндә генә, татар телен укытуның сыйфатын яхшыртып, урта гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучы укучыларны татар теленнән Бердәм республика имтиханын (БРИ) уңышлы тапшырырга әзерләп була. Бердәм республика имтиханы 3 өлештән тора (А, Б, С). *А* өлешендәге тестлар укучыларның гамәли белемнәрен, сөйләм нормаларын үзләштерүне тикшерүгә юнәлтелгән; *В* өлешендәге биремнәр, укылган текстка нигезләнеп, тел берәмлекләренең кулланылышын дөрес билгеләүне үз эченә ала; ә *С* өлешендә укучылар, укылган текстның эчтәлегеннән чыгып, анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтләрен белдереп, иншa язарга тиешләр.

# 5 нче СЫЙНЫФ (175 сәгать)

## АРАЛАШУ ТЕМАЛАРЫ

1. Яңа уку елы белән!
2. Кеше һәм сәламәтлек.
3. Өйдә һәм кунакта.
4. Туган ягыбызның табигате.
5. Татарстан — минем республикам.
6. Уйныйбыз да, биибез дә.
7. Һөнәрләр дөньясында.
8. Музейлар һәм театрлар.
9. Сәяхәт итү.
10. Җәй.
11. Татар балалар язучылары һәм шагыйрьләре.

## ЛЕКСИК МИНИМУМ

**1. Яңа уку елы белән!** (15 сәгать)

аваз, хәреф, сузык, тартык, яңгырау, саңгырау, калын, нечкә, искә төшерергә, истә тотарга, кулланырга, кагыйдә, барысы да, һәрбер, сыйныфташ, димәк, котларга, теләргә, уңыш, ярыйсы, уртача, шәп, беркөе

**2. Кеше һәм сәламәтлек** (15 сәгать)

сәламәт, гәүдә, каш, керфек, ирен, тән, терсәк, яңак, тез, саф һава, чиста, күзлек, уңайлы, шатланырга, елмаерга, өлкән, олы, чыныгырга, шөгыльләнергә, йөзү, йөгерү

**3. Өйдә һәм кунакта** (15 сәгать)

рәхим итегез, рөхсәт итәргә, гафу итәргә, гафу үтенергә, сыйларга, сый, әзерләргә, әзер, пешерергә, авыз итәргә, кунакчыл, кунак итәргә, урнаштырырга, табын, куярга, бергәләп, чын күңелдән, зинһар өчен, өченчекөн, берсекөнгә

**4. Туган ягыбызның табигате** (15 сәгать)

ала карга, песнәк, чәүкә, саескан, урман тавыгы, ач, ачлык, үләргә, үлән, үсемлек, бака яфрагы, гүзәл, гүзәллек, нәфис, нәфислек, сокланырга, тигез, иркен, алан, бурсык, җәнлек, дала

**5. Татарстан — минем республикам** (15 сәгать)

милләт, төрле, тату, җитештерелергә, төзелергә, мул, уңыш (урожай), якын (около), артык (более), билгеле (танылган), очратырга, күрсәтергә, озынлык, тирәнлек, биеклек

**6. Уйныйбыз да, биибез дә** (15 сәгать)

тиздән, көлкеле, әйбер, каршыларга, сикерү, чүлмәк вату, көрәш, аркан тартышу, катнашырга, чыгыш ясарга, ятларга, дәвам итәргә, түзәргә, тәбрикләргә, шатланырга

**7. Һөнәрләр дөньясында** (15 сәгать)

белгеч, нәшрият, китапханә, китапханәче, остаханә, кулъязма, тарихчы, хәрби хезмәткәр, янгын сүндерүче, хәбәрче, игенче, терлекче, урам себерүче, җыештыручы

**8. Музейлар һәм театрлар** (15 сәгать)

тарих, тарихи, әдәбият, әдәби, милли, милләт, фән, фәнни, борынгы, әйбер, хәзинә, кызыклы, рәсем, рәсем ясарга, карачкы, төрле, башка (другой), таныштырырга, төрле, корал, дөнья

**9. Сәяхәт итү** (15 сәгать)

юл, юлчы, юлдаш, хыял, хыялланырга, ышанырга, озатырга, тимер юл вокзалы, елга порты, ил, чит ил, инглиз, кытай, гарәп, төрек, диңгез, ял йорты

**10. Җәй** (15 сәгать)

ком, комлык, кызынырга, су коенырга, балык тотарга, сөенергә, чикерткә, күбәләк, черки, чебен, эссе, күләгә, җиләс, учак ягарга, күк, йолдыз, орлык чәчәргә, үстерергә, беренчедән, икенчедән, өченчедән, минемчә, синеңчә

**11. Татар балалар язучылары һәм шагыйрьләре** (25 сәгать)

хәтердә калдырырга, тормыш юлы, иҗат, иҗат итәргә, әдәби, әсәр, хикәя, мәсәл, чынбарлык, кимчелек, уңай сыйфатлар, тискәре, көлке хәл, тапкыр (находчивый), булдыклы, булдыксыз, надан, алдакчы, саран, юмарт, ошарга, эзләргә, табарга

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Сан, тартым белән төрләнгән исемнәргә килеш кушымчаларын ялгау тәртибен үзләштерү (*апа + лар + ым + ны; дәф + тәр + ләр + егез + гә; гимназия + ләр + ебез + дә*).
2. Зат алмашлыкларын җөмлә төзүдә куллану үзенчәлекләрен аңлату (*Бу — абыем.* ***Аның*** *исеме — Марат.* ***Бу*** *—* ***безнең*** *мәктәп. Ул яңа.* ***Без аны*** *яратабыз*).
3. Берлек һәм күплек сандагы тартымлы исемнәрне сөйләмдә дөрес куллануга ирешү. Тартым кушымчасының рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләрен искәртү.

4. Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр белән кулланып, җөмлә төзергә күнектерү: *барырга кирәк (кирәкми), алырга ярый (ярамый), сөйләргә тиеш (түгел).*

5. Хикәя фигыльнең заман формаларын сөйләмдә дөрес куллануга ирешү.

6. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта-юклыкта затсан белән төрләнешен гамәли үзләштерү.

7. *Буенда, буйлап, буенча* бәйлек сүзләрен урынлы куллануга ирешү.

8. *Бәлки, билгеле, димәк, беренчедән, икенчедән, минемчә, синеңчә* кебек кереш сүзләрне сөйләмгә кертү.

9. *-даш/-дәш, -таш/-тәш (сыйныфташ, юлдаш); -лык/-лек (дуслык, шатлык)* кушымчалы исемнәрне үзләштерү; кушма *(башваткыч, тизәйткеч)* һәм парлы *(бала-чага)* исемнәрнең мәгънәләренә төшендерү.

10. Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.

11. Хикәя, боеру, сорау җөмләләрдә сүз тәртибе үзенчәлекләрен рус теле белән чагыштырып өйрәтү.

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

1,5—2 минутлык бәйләнешле текстны тыңлап, эчтәлеге буенча укытучының сорауларына җавап бирү яки сөйләү;

дәрестә җанлы сөйләмне аңлап аралашу.

### Диалогик сөйләм

Сорау һәм җавап репликаларын дөрес кулланып, тәкъдим ителгән ситуация буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 7 дән ким булмаска тиеш);

укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча әңгәмә кору.

### Монологик сөйләм

Җыйнак җөмләләрне җәенкеләндереп, хикәя төзү;

лексик тема буенча бәйләнешле текст төзеп сөйләү (җөмләләр саны 8 дән ким булмаска тиеш);

укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген сөйләп бирү.

### Уку

Төрле жанрлардагы текстларны сәнгатьле итеп һәм тулысынча аңлап уку; төп мәгълүматны табып әйтү;

татар балалар язучылары һәм шагыйрьләре турында уку;

әдәби әсәрләрдән алынган өзекне укып, андагы вакыйгалар турында кыскача әйтеп бирү;

шигырьләрне яттан сөйләү.

### Язу

Актив үзләштерелгән сүзләрдән диктант язу;

лексик тема буенча хикәя язу;

укылган (тыңланган) текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУ

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары**:

1) татар әдәбияты әсәрләре аша укучыларны татар халкының тарихы, рухи казанышлары, тормыш-яшәеш үзенчәлекләре белән таныштыру;

2) укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен һәм осталыкларын камилләштерү, фикер эшчәнлеген үстерү, татар телен укытуның сыйфатын яхшырту;

3) татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр һәм аларның авторлары турында мәгълүматлы булу;

4) гомумкешелек әхлакый сыйфатлар тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның дөньяга карашын формалаштыру, аларда уңай сыйфатлар булдыру, әдәбиятка кызыксынуларын арттыру;

5) танылган язучы һәм шагыйрьләрнең иҗаты, тормыш юлы турында кыскача белешмә бирү;

6) вакытлы матбугат язмаларын, мәгълүмати текстларны укырга һәм аларга күзәтү ясарга, анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтен дәлилләп белдерергә күнектерү.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Татар әдәбиятын өйрәнү өчен эчтәлек сайлау әдәбият белемендә кабул ителгән эстетик һәм әдәби принципларга бәйле.

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: әкиятләр, теләкләр, тизәйткечләр, санамышлар.

Төрле әдәби жанрлардагы әсәрләрдән (хикәя, повесть, роман, драма) әхлакый проблеманы үз эченә алган өзекләр.

Татар әдипләренең әсәрләре: **К. Насыйри.** «Хикәят», «Патша белән карт»; **Г. Тукай.** «Су анасы», «Кәҗә белән сарык», «Эшкә өндәү», «Сабыйга»; **Г. Ибраһимов.** «Яз башы»; **М. Җәлил.** «Кызыл ромашка», «Имән», «Алтынчәч» (өзек); **Ф. Кәрим.** «Кыр казы», «Үлем турында уйлама»; **А. Алиш.** «Чуар тавык», «Сертотмас үрдәк»; **Ф. Хөсни.** «Чыбыркы»; **Ф. Яруллин.** «Зәңгәр күлдә ай коена», «Ике чәчәк»; **М. Әгъләм.** «Инешнең илгә кайтуы», «Матурлык минем белән»; **Н. Исәнбәт.** «Мыраубай батыр», «Туган ил», «Әбием янында»; **Н. Дәүли.** «Бәхет кайда була?»; **Р. Миңнуллин.** «Аяз кайта мәктәптән», «Берәү, икәү өчәү...», «Туган тел»; **Д. Аппакова.** «Рөстәм».

Биографик белешмәләр: **К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ф. Хөсни, А. Алиш, Ф. Яруллин, Р. Миңнуллин.**

Рус язучыларының тәрҗемә әсәрләре: **А. Платонов.** «Ягъфәр бабай»; **А. Гайдар.** «Зәңгәр чынаяк».

Дөнья әдәбияты классикларының тәрҗемә әсәрләре: **М. Твен. «Том Сойер мажаралары».**

Прагматик текстлар: белдерүләр, реклама үрнәкләре.

Эпистоляр жанр текстлары: котлаулар.

# 6 нчы СЫЙНЫФ (175 сәгать)

## АРАЛАШУ ТЕМАЛАРЫ

1. Белем һәм хезмәт.
2. Сәламәтлек — зур байлык.
3. Туганлык мөнәсәбәтләре.
4. Кешенең рухи дөньясы.
5. Табигать — безнең йортыбыз.
6. Бакча эшләре.
7. Авыл тормышы.
8. Татарстан Республикасы.
9. Татар халкының күренекле шәхесләре.
10. Татар балалар язучылары һәм шагыйрьләре иҗатыннан.

### ЛЕКСИК МИНИМУМ

**1. Белем һәм хезмәт** (15 сәгать)

белем алырга, кабатларга, уйларга, тәрҗемә итәргә, төзәтергә, файдаланырга, кулланырга, хәтер, хәтерләргә, яттан, ятларга, атаклы, танылган, нәтиҗә, нәтиҗәдә, кызганыч, кызганычка каршы, бәхеткә каршы, киресенчә

**2. Сәламәтлек — зур байлык** (15 сәгать)

шифаханә, хастаханә, шәфкать туташы, шәфкатьле, шифалы, әрекмән, тузганак, үги ана яфрагы, җыярга, киптерергә, кайнатырга, кәеф, хис итәргә, таләп, үтәргә, төгәл, сакланырга, хәл, тәэсир итәргә, аркасында, сәбәп, сәбәпле, гадәт, шуңа күрә, исән-сау булырга

**3. Туганлык мөнәсәбәтләре** (15сәгать)

кардәш, туганнан туган, бертуган, бердәнбер, онык, игезәк, кияү, кәләш, кияүгә чыгарга, өйләнергә, туй, юмарт, саран, ялгыз, гореф-гадәт, өй туе, бәби туе, каз өмәсе

**4. Кешенең рухи дөньясы** (15 сәгать)

рухи, теләк, теләргә, иҗат итәргә, уздырырга, үткәрергә, бушка, юкка, омтылырга, маҗара, башваткыч, фотога төшерергә, башка (бүтән), соң (поздно), бигрәк тә (аеруча), каршы булырга, лаек булырга, хаклы булырга, заманча, аралашырга, хәбәрләшергә

**5. Табигать — безнең йортыбыз** (15 сәгать)

ел фасылы, кар күмә, боз каплый, кар бөртеге, һәр, һәркем, һәрвакыт, кайвакыт, кар эри, гөрләвек ага, кош-корт, бал корты, кырмыска,

сайрарга, тургай, ау, ауларга, атарга (стрелять), чүл, әрәмә, алан, куаклык, Идел, Мишә, Агыйдел, Нократ

**6. Бакча эшләре** (15 сәгать)

казырга, көрәк, түтәл ясарга, утыртырга, орлык, су сибәргә, су сипкеч, чүп үләне, чүп утарга, тырмаларга, тырма, эшчән, ялкау, май коңгызы, бөҗәк, бал корты, чикерткә

**7. Авыл тормышы** (15 сәгать)

ишегалды, капка, сарай, койма, мунча, чиләк, кыр (басу), иген, игенче, үстерергә, ашлык, борчак, чөгендер, көнбагыш, кукуруз, урыпҗыю, терлекче, дуңгыз, көтү, көтү көтәргә, ашатырга, эчерергә, ат карарга, печән чабарга

**8. Татарстан Республикасы** (15 сәгать)

милләт, күпмилләтле, күпчелек, ил башлыгы, җитәкче, эшкуар, хөкүмәт, сәясәт, икътисад, мәдәният, сәяси, мәдәни, фәнни, үсеш алырга, дәүләт теле, тигез хокуклы, халыкара, кабул итәргә, билгеләп үтәргә, горурланырга

**9. Татар халкының күренекле шәхесләре** (15 сәгать)

шәхес, күренекле, вәкил, мәгърифәтче, нигез салучы, бөек, дан, дан казанырга, көч куярга, өлеш кертергә, иҗат итәргә, киңәш, киңәшче, киңәш итәргә, казаныш, үрнәк алырга, сәхнә остасы, галим

**10. Татар балалар язучылары һәм шагыйрьләре иҗатыннан** (40 сәгать)

шагыйрь, язучы, балалар язучысы, чит ил язучысы, өзек, бүлек, эчтәлек, төп, кыскача, тулысынча, ошарга, геройның холкы, китап укучы, китап киштәсе, тәкъдим итәргә, риза булырга, кайтарырга, сорап торырга, алып торырга

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Төрле килешләрдәге тартымлы исемнәрне сөйләмдә дөрес кулланырга күнектерү.

2. Асыл сыйфатларны чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләрендә дөрес әйтергә, язарга һәм сөйләмдә кулланырга күнектерү.

3. Микъдар, тәртип, җыю саннарының кулланылышын кабатлау.

4. Бүлем һәм чама саннарын гамәли үзләштерү.

5. Билгеләү *(һәр, һәркем, барлык, бөтен, үз),* билгесезлек *(кемдер, кайчандыр, әллә кем, әллә нәрсә),* юклык *(беркая, берничек)* алмашлыкларын гамәли үзләштерү.

6. Хикәя фигыльнең хәзерге, билгеле һәм билгесез үткән заман, билгеле һәм билгесез киләчәк заман формаларын сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.

7. Шарт фигыльне (*-са/-сә)* сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

8. Теләк фигыльне *(барыйм әле, килим әле)* сөйләмдә куллану күнекмәләре булдыру.

9. Боерык фигыльне барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләндереп кулланырга күнектерү.

10. Фигыль һәм исем хәбәрләрнең гади, кушма һәм тезмә төрләрен танып белергә өйрәтү.

11. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.

12. *Башка, бүтән, бирле, соң, таба, каршы* бәйлекләрен, *сәбәпле, аркасында* бәйлек сүзләрен урынлы куллануга ирешү.

13. Кереш сүзләрдән файдаланырга күнектерү.

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

Ике минутлык текстны тыңлап, эчтәлеген эзлекле итеп телдән яки язмача сөйләп бирү;

төрле жанрлардагы текстларны тыңлап аңлау һәм эчтәлеге буенча биремнәр башкару.

### Диалогик сөйләм

Җәенкеләндерелгән репликаларны кулланып, аралашу ситуациясе буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 8 дән ким булмаска тиеш);

сөйләм гыйбарәләрен урынлы кулланып, диалог төзеп сөйләү.

### Монологик сөйләм

Лексик тема буенча хикәя төзеп сөйләү (җөмләләр саны 9 дан ким булмаска тиеш);

тасвирлау, хикәяләү, фикер йөртү элементларын кертеп, укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген сөйләү;

шигырьләрне яттан сөйләү.

### Уку

Төрле жанрлардагы текстларны сәнгатьле итеп һәм эчтәлегенә тулысынча төшенеп уку;

укылган текстның эчтәлегенә, анда күтәрелгән мәсьәләләргә, төп геройларына карата үз мөнәсәбәтеңне белдерү;

татар балалар әдәбиятының күренекле вәкилләре турында сөйләү.

### Язу

Лексик тема буенча бәйләнешле текст язу;

җөмлә калыпларын, бәйләнешле текстларны үзгәрешләр кертеп язу.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУ

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары**:

1) татар әдәбияты әсәрләре аша укучыларны татар халкының тарихы, рухи казанышлары, тормыш-яшәеш үзенчәлекләре белән таныштыру;

2) укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен һәм осталыкларын камилләштерү, фикер эшчәнлеген үстерү, татар телен укытуның сыйфатын яхшырту;

3) татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр һәм аларның авторлары турында мәгълүматлы булу;

4) гомумкешелек әхлакый сыйфатлар тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның дөньяга карашын формалаштыру, аларда уңай сыйфатлар булдыру, әдәбиятка кызыксынуларын арттыру;

5) танылган язучы һәм шагыйрьләрнең иҗаты, тормыш юлы турында кыскача белешмә бирү;

6) вакытлы матбугат язмаларын, мәгълүмати текстларны укырга һәм аларга күзәтү ясарга, анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтен дәлилләп белдерергә күнектерү.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Татар әдәбиятын өйрәнү өчен эчтәлек сайлау әдәбият белемендә кабул ителгән эстетик һәм әдәби принципларга бәйле.

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: тизәйткечләр, табышмаклар, санамышлар.

Төрле әдәби жанрлардагы әсәрләрдән (хикәя, повесть, роман, драма), әхлакый проблеманы үз эченә алган өзекләр.

Татар әдипләренең әсәрләре: **Г. Тукай.** «Шүрәле», «Туган авыл»; **М. Гафури.** «Ана», «Сарыкны кем ашаган?»; **Һ. Такташ.** «Мокамай»; **М. Җәлил.** «Балалар, вакытында уйнагыз...», «Имән», «Чәчәкләр»; **Ә. Еники.** «Матурлык»; **Г. Бәширов.** «Безнең Татарстан», «Сабантуй»; **Ш. Маннур.** «Исәнмесез, минем шаян дуслар!», «Яшь туристлар җыры», «Кошлар килде», «Иң матур җыр»; **Г. Афзал.** «Суларда йөз, эшлә кырда!»; **И. Гази.** «Онытылмас еллар»; **М. Мәһдиев.** «Фронтовиклар»; **Ф. Яруллин.** «Өмәләр»; **Ш. Галиев.** «Кунаклар», «Кеше урман кисә», «Буш кеше», «Рәсем ясадым»; **Г. Гыйльманов.** «Ана», «Әнкәй образы», «Иртәнге әкият».

Биографик белешмәләр: **Һ. Такташ, Ш. Маннур, М. Гафури, Ә. Еники, Ш. Галиев, М.Мәһдиев.**

Рус язучыларының тәрҗемә әсәрләре: **А.Чехов.** «Анюта»; **С. Радзиевская.** «Урман хикәясе»; **В. Распутин.** «Француз теле дәресләре».

Дөнья әдәбияты классикларының тәрҗемә әсәрләре: **Д. Свифт. «Гулливер лилипутлар илендә»; Э. Сетон-Томпсон. «Бинго».**

Прагматик текстлар: рецептлар, радио һәм телевидение программалары, белдерүләр, реклама үрнәкләре.

Эпистоляр жанр текстлары: шәхси һәм рәсми хатлар.

# 7 нче СЫЙНЫФ (175 сәгать)

АРАЛАШУ ТЕМАЛАРЫ

1. Белем һәм тормыш.
2. Өлкәннәр һәм кечкенәләр.
3. Табигать һәм кеше.
4. Ял итү.
5. Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше.
6. Син һәм синең яшьтәшләрең.
7. Ел фасыллары.
8. Татарстанның казанышлары.
9. Сәүдә үзәгендә.
10. Татар әдипләре иҗатыннан.

**ЛЕКСИК МИНИМУМ**

**1. Белем һәм тормыш** (15 сәгать)

мәгариф, мөгаллим, шәкерт, мәгълүмат, катлаулы, төшенергә, тасвирларга, фикер йөртергә, фикер алышырга, күчереп язарга, тәҗрибә, тәҗрибәле, мәсәлән, мисал өчен, имтихан бирергә, чирек, түгәрәк (кружок), сочинение, мәкалә

**2. Өлкәннәр һәм кечкенәләр** (15 сәгать)

шәҗәрә, нәсел, өлкән, олы, кече, туган-тумача, таныш-белеш, кадерләргә, хезмәттәш, лаеклы ял, пенсиягә чыгарга, кода, кодагый, каенана, каената, кешелекле, гадел, җитди, сөйкемле, холык, уңай, сыйфат (качество), ханым, әфәнде, туташ

**3. Табигать һәм кеше** (15 сәгать)

кешелек, иксез-чиксез, кадерен белергә, чара күрергә, пычратырга, зарарлы, матдә, тыюлык, тыярга, каршы торырга, бушлык, чишмә, күл, бөркет, карлыгач, күке, тукран, торна, болан, ак төлке

**4. Ял итү** (15 сәгать)

күңел ачарга, күңел ачу үзәге, бергәләп, моң, көй, үзешчән сәнгать, тылсымлы, мәхәббәт, зәвык, зәвыклы, Нәүрүз бәйрәме, Сөмбелә бәйрәме, халыкчан, багышларга, башланырга, тәмамланырга, дәвам итәргә

**5. Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше** ( 15 сәгать)

спортчы, чаңгычы, тимераякта шуучы, хоккейчы, футболчы, көрәшче, йөзүче, җиңәргә, җиңелергә, көндәш, беренчелек, исәп, алка

(шайба), Спорт сарае, Боз сарае, фигуралы шуу, тау чаңгысы, су чаңгысы

**6. Син һәм синең яшьтәшләрең** (15 сәгать)

яшьтәш, мөнәсәбәт, тыгыз, ышанычлы, урнаштырырга, дуслашырга, дус-иш, сәламләргә, бергә, буш вакыт, әңгәмә корырга, бәхәсләшергә, дөреслек, эзләргә, табарга, аңлатырга

**7. Ел фасыллары** (15 сәгать)

ел фасылы, якынлашырга, үтәргә, кырау, томан, яшен, буран, салават күпере, һава торышы, офык, вакыт-вакыт, көнаралаш, көннән-көн, юеш, дымлы, коры, искиткеч, ләззәтләнергә, сокланырга, күз алдына китерергә, куанырга

**8. Татарстанның казанышлары** (15 сәгать)

казаныш, икътисад, икътисади, югары сыйфатлы, йөк машиналары, җиңел машиналар, әйбер, тегү әйберләре, күн әйберләре, йорт җиһазлары, көнкүреш кирәк-яраклары, азык-төлек, алыш-биреш, исәп-хисап, көндәшлек, салым, керем, чыгым, табыш, бурычка алырга, акча күчерергә, акча алмаштырырга, күпләп сатарга, хосусыйлаштырырга, хосусый, алдынгы, эшсез, эшсезлек

**9. Сәүдә үзәгендә** (15 сәгать)

сәүдә, сәүдә итәргә, сәүдәгәр, сәүдәгәрлек, сатып алучы, баш киеме бүлеге, аяк киеме бүлеге, өс киеме бүлеге, заманча, модалы, ташлама, түләүле, түләүсез, ярминкә, кыйбат, кыйммәтле, арзан, бәя (хак), артык (слишком), акчасыз, акчасызлык

**10. Татар әдипләре иҗатыннан** (40 сәгать)

матур әдәбият, дөньякүләм танылган, әдип, вәкил, тәнкыйть, тәнкыйтьче, тәнкыйтьләргә, иҗат эшчәнлеге, иҗади, танылу алырга, сурәтләргә, яктыртырга, дан җырларга, кайгыртырга, язмыш, күпкырлы, күп санлы, үзенчәлекле, мактаулы исем, лаек булырга, тормышчан, тирән эчтәлекле

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.
2. Аныклагыч белән таныштыру. Аныклаучы теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләрне *(ягъни, аеруча, бигрәк тә)* кулланып, җөмләләр төзергә һәм аныклагычлар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү.
3. Кушма *(бөтендөнья),* парлы *(туган-тумача, алыш-биреш, азык-төлек, мал-туар)* исемнәрнең сөйләмдә куллану үзенчәлекләрен үзләштерү.
4. Лексик темаларга караган сыйфатларның исемләшүен аңлату.
5. Хикәя фигыльнең үткән заман формаларын, барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләндереп, сөйләмдә урынлы куллануга һәм рус теленә дөрес тәрҗемә итүгә ирешү.

6. Хикәя фигыльнең киләчәк заман формаларын сөйләмдә барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләндереп кулланырга күнектерү.

7. Хикәя фигыльнең үткән һәм киләчәк заман формаларын аера белү һәм, фикерне төгәл белдерү өчен, сөйләмдә куллану күнекмәләрен камилләштерү.

8. Сыйфат фигыльнең заман формалары белән таныштыру һәм аларны куллану үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү.

9. Хәл фигыль формаларын кулланып, сөйләм булдыруга ирешү.

10. Исем фигыльне сөйләмдә куллану һәм аның рус теленә тәрҗемә ителү үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү.

11. Теләк (*барасым килә*), ният (*бармакчы булам*), мөмкинлек/мөмкин түгеллек (*бара алам, бара алмыйм*), кирәклек/кирәк түгеллек (*барасым бар, барасым юк*), боеру (*барасы бул, барасы булма*) мәгънәләрен белдерә торган аналитик фигыльләрне дөрес кулланырга һәм тәрҗемә итәргә күнектерү.

12. Процессның башлануын, дәвам итүен, тәмамлануын белдерә торган аналитик фигыльләрне *(укый башлады, укып ята, укып бетерде)* танып белергә һәм сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

13. Эндәш, кереш сүзләрне сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.

14. Җыючы *(һәм, вә, да/дә, та/тә, ни ... ни),* каршы куючы *(ләкин, ә, әмма, тик),* бүлүче *(я, яки, яисә)* теркәгечләр белән җөмләләр төзү күнекмәләрен системалаштыру.

15. Синонимнарны, антонимнарны сөйләмдә куллануга ирешү.

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

Аралашуда катнашучыларның сөйләмен тыңлап аңлап, үз фикереңне аңлаешлы белдерү;

өч минутлык текстны тыңлап, аның төп эчтәлегенә караган биремнәрне телдән яки язмача эшләү.

### Диалогик сөйләм

Төрле репликаларны кулланып, лексик темага сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 9 дан ким булмаска тиеш);

сөйләшү барышында үз фикереңне төгәл һәм эзлекле белдерү.

### Монологик сөйләм

Тәкъдим ителгән темага монолог төзеп сөйләү (җөмләләр саны 10 нан ким булмаска тиеш);

өстәмә чыганаклардан һәм вакытлы матбугаттан файдаланып, яңалыклар турында хәбәр итү;

укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген кыскача яки тулысынча сөйләү.

### Уку

Төрле жанрлардагы текстларны эчтән уку һәм эчтәлеген кыскача сөйләп бирү;

текст белән танышып чыгып, эчтәлеге буенча төп мәгълүматны әйтеп бирү;

татар әдипләренең иҗаты турында белгәннәрне әйтеп бирү;

шигырьләрне яттан сөйләү.

### Язу

Лексик темаларга караган сүзләрне дөрес язу;

укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген язмача сөйләп бирү;

тәкъдим ителгән темага инша язу;

аралашу гыйбарәләрен кулланып, хат язу.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУ

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары**:

1) татар әдәбияты әсәрләре аша укучыларны татар халкының тарихы, рухи казанышлары, тормыш-яшәеш үзенчәлекләре белән таныштыру;

2) укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен һәм осталыкларын камилләштерү, фикер эшчәнлеген үстерү, татар телен укытуның сыйфатын яхшырту;

3) татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр һәм аларның авторлары турында мәгълүматлы булу;

4) гомумкешелек әхлакый сыйфатлар тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның дөньяга карашын формалаштыру, аларда уңай сыйфатлар булдыру, әдәбиятка кызыксынуларын арттыру;

5) танылган язучы һәм шагыйрьләрнең иҗаты, тормыш юлы турында кыскача белешмә бирү;

6) вакытлы матбугат язмаларын, мәгълүмати текстларны укырга һәм аларга күзәтү ясарга, анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтен дәлилләп белдерергә күнектерү.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Татар әдәбиятын өйрәнү өчен эчтәлек сайлау әдәбият белемендә кабул ителгән эстетик һәм әдәби принципларга бәйле.

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: әкият, мәкаль, әйтем, сынамыш.

Төрле әдәби жанрлардагы әсәрләрдән (хикәя, повесть, роман, драма) әхлакый проблеманы үз эченә алган өзекләр.

Татар әдипләренең әсәрләре: **Г. Тукай.** «Милли моңнар»; **Г. Ибраһимов.** «Табигать балалары»; **С. Хәким.** «Бакчачылар», «Янар өчен илһам эзли диләр»; **Һ. Такташ.** «Иптәшләр», «Алсу»; **Ф. Кәрим.** «Үлем уены»; **Г. Кутуй.** «Рәссам»; **Ә. Еники.** «Кем җырлады?»; **Г. Бәширов.** «Менә сиңа мә!»; **Г. Әпсәләмов.** «Алтын йолдыз»; **Ф. Хөсни.** «Малай белән солдат»; **И. Гази.** «Йолдызлы малай»; **Ә. Баянов.** «Тау ягы повесте», «Сәяхәтнамә»; **М. Мәһдиев.** «Без — кырык беренче ел балалары»; **Ф. Яруллин.** «Яралы язмышлар»;

**М. Галиев.** «Нигез»; **М. Әгъләм.** «Тукайдан хатлар»; **Т. Миңнуллин.** «Монда тудык, монда үстек», «Минһаҗ маҗаралары».

Биографик белешмәләр: **Г. Тукай, С. Хәким, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, Т. Миңнуллин, Р. Миңнуллин.**

Рус язучыларының тәрҗемә әсәрләре**: А. Пушкин.** «Кышкы кич», «Тоткын»; **Д. Мамин-Сибиряк.** «Ялгызак», **К. Паустовский.** «Алама чыпчык».

Дөнья әдәбияты классикларының тәрҗемә әсәрләре: **Д. Дефо.** «Диңгез гизүче Робинзон Крузоның тормышы һәм аның башыннан кичкән гаҗәп хәлләр»; **Э. Распэ.** «Барон Мюнхгаузен маҗаралары».

Прагматик текстлар: рецептлар, радио һәм телевидение программалары, белдерүләр, реклама үрнәкләре.

Эпистоляр жанр текстлары: шәхси һәм рәсми хатлар, эш кәгазьләре.

# 8 нче СЫЙНЫФ (175 сәгать)

АРАЛАШУ ТЕМАЛАРЫ

1. Белем һәм фән.
2. Кешенең холкы.
3. Гаилә этикасы.
4. Яраткан шөгыльләребез.
5. Табигатьне саклау.
6. Рәсми сөйләм.
7. Татарстан шәһәрләре.
8. Татарстанның казанышлары.
9. Халыкка багышланган гомер.
10. Татар әдипләре иҗатыннан.

## ЛЕКСИК МИНИМУМ

**1. Белем һәм фән** (15 сәгать)

уку-язу әсбаплары, кулланма, уйланырга, хәл итәргә, үзләштерергә, гамәли, күнегергә, дәлилләргә, каршы килергә, тынычландырырга, күләмле, камил белергә, тикшеренү, чыгыш ясарга, белгеч, белгечлек

**2. Кешенең холкы** (15 сәгать)

холык, намуслы, ихтирамлы, түземле (сабыр), түземлек, уйчан, максатчан, өлгер, горур, үткен, ягымлы, оялчан, тәкәббер, тупас, явыз, үзсүзле, ваемсыз, игътибар күрсәтергә, яхшылык, игелекле, борчырга, гаепләргә, начарлык, ия булырга, уңай, тискәре

**3. Гаилә этикасы** (15 сәгать)

мәхәббәт, хатын, ир, гомер итәргә (көн итәргә), үзара аңлашу, кайгыртырга, тәрбияләргә, тугры, тугрылык, итагатьле, юл куярга, үкенергә, югалтырга, битараф, бәяләргә, күп балалы, үги бала, үги әни, үги әти, ятим, ятимлек, мәнфәгать

**4. Яраткан шөгыльләребез** (15 сәгать)

шөгыль, мавыктыргыч, максат куярга, ирешергә, сүз бирергә, көч куярга, тормышка ашырырга, нәтиҗәле, гаҗәпләнергә, фаразларга, сарыф итәргә, еш, сирәк, кайвакыт, һәрвакыт, даими, мөрәҗәгать итәргә, шәхес, рәхәтләнеп

**5.Табигатьне саклау** (15 сәгать)

киләчәк, мохит, тынлык, үзгәреш, кискен, янгын, җир тетрәү, сакчыл, сак булырга, үсенте, чирәм, оя, коткарырга, сусаклагыч, җир-су, коточкыч, зарарланырга, ташларга, имгәтергә, үтерергә, торгызырга

**6. Рәсми сөйләм** (15 сәгать)

сөйләм, рәсми, әдәби, гади, җирле, җыелыш, утырыш, мәҗлес, корылтай, идарә итәргә, рәис, рәсми кәгазь, белдерү, расларга, имза куярга, карар, беркетмә, аңлатма язуы, ышаныч язуы, таныклык, җаваплылык, сәркатип, вазифа, тавыш бирергә, кабул итәргә

**7. Татарстан шәһәрләре** (15 сәгать)

көньяк-көнчыгыш, көньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш, төньяк-көнбатыш, чикләшергә, чик, тоташтырырга, бәйләргә, нигез салырга, бүленергә, өлеш, мәйдан, мәйданчык, күпер, яр, данлыклы, таш дивар, тартып торырга, сокландыргыч, гаҗәеп

**8. Татарстанның казанышлары** (15 сәгать)

эре, тармак, машина төзелеше, алга китәргә, алдынгы, эшкәртергә, эшләп чыгарырга, куәтле, матди, чимал, ягулык, арадашчы, арадашлык итәргә, тәртипкә салырга, бәйләнеш, элемтә, турыдан-туры, ныгытырга, киңәйтергә, хезмәттәшлек итәргә, килешү төзергә, өлкә, төбәк

**9. Халыкка багышланган гомер** (20 сәгать)

хәзинә, ачыш ясарга, өлеш кертергә, тынгысыз, бертуктаусыз, эзләнергә, чын, дөнья күрергә, җитәкчелек итәргә, билгеләп үтәргә, бүгенге, кичәге, киләсе, буын, хезмәт, дәүләт бүләге, олы җанлы, үлемсез, кабатланмас, искә алырга, оештыручы

**10.Татар әдипләре иҗатыннан** (35 сәгать)

әдәбиятчы, әдәби-нәфис, бай, мирас, нәшрият, матбугат, җыентык, эшлекле, эшчәнлек, чара, баетырга, замандаш, төркем, тупларга, рухи, бөеклек, көчле рухлы, авырлык, җиткерергә, фикер алышырга

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аера белергә өйрәтү.
2. Кушма исем һәм кушма фигыль хәбәрләрне билгеләргә күнектерү.
3. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләрне сөйләмдә дөрес куллануга ирешү.
4. Аналитик фигыльләрне сөйләмдә аңлап кулланырга һәм рус теленә тәрҗемә итәргә өйрәтү.
5. Фигыльнең төшем һәм йөкләтү юнәлешләрен гамәли үзләштерү.
6. Тәрҗемәле, антонимнар, синонимнар, фразеологик һәм башка төр сүзлекләрдән файдаланырга күнектерү.
7. Бер составлы фигыль җөмләнең сөйләмдә актив кулланыла торган төрләрен гамәли үзләштерү.

8. Атау җөмләләрне сөйләмдә танып белергә өйрәтү.

9. Диалогик сөйләмгә хас булган сүз җөмләләр белән таныштыру.

10. Тулы һәм ким, җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аера белергә гадәтләндерү.

11. Татар җөмләсендә сүз тәртибе үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү.

12. Туры сөйләм турында мәгълүмат җиткерү.

13. Актив үзләштерелгән сүзләрнең синонимнарын, антонимнарын, фразеологик берәмлекләрне сөйләмдә куллануга ирешү.

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

Өч минутлык текстны тыңлап, аның эчтәлеге буенча сөйләшү (полилог) үткәрү;

диктор сөйләмен тыңлап, эчтәлеге буенча мөстәкыйль эшләр эшләү.

### Диалогик сөйләм

Укылган (тыңланган) текстның эчтәлеге буенча фикер алышуда катнашу;

кара-каршы сөйләшү барышында аралашу максатына ирешү һәм үз фикереңне белдерү;

тәкъдим ителгән ситуация буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 10 нан ким булмаска тиеш).

### Монологик сөйләм

Табигать күренешләрен, төрле вакыйгаларны тасвирлау;

иҗтимагый һәм мәдәни тормыш яңалыклары турында хәбәр итү (җөмләләр саны 12 дән ким булмаска тиеш);

укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген эзлекле итеп сөйләп бирү.

### Уку

Әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрнең, фәнни-популяр текстларның эчтәлеген тулысынча аңлап уку, кирәкле мәгълүматны табып әйтү;

шигырьләрне яттан өйрәнү һәм сәнгатьле итеп сөйләү.

### Язу

Лексик темага караган бәйләнешле текст язу;

укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген язу;

бирелгән үрнәк буенча рәсми кәгазьләрне (тәрҗемәи хәл, белдерү, белешмә, аңлатма язуы) язу;

котлау (чакыру) хатлары язу.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУ

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары**:

1) татар әдәбияты әсәрләре аша укучыларны татар халкының тарихы, рухи казанышлары, тормыш-яшәеш үзенчәлекләре белән таныштыру;

2) укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен һәм осталыкларын камилләштерү, фикер эшчәнлеген үстерү, татар телен укытуның сыйфатын яхшырту;

3) татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр һәм аларның авторлары турында мәгълүматлы булу;

4) гомумкешелек әхлакый сыйфатлар тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның дөньяга карашын формалаштыру, аларда уңай сыйфатлар булдыру, әдәбиятка кызыксынуларын арттыру;

5) танылган язучы һәм шагыйрьләрнең иҗаты, тормыш юлы турында кыскача белешмә бирү;

6) вакытлы матбугат язмаларын, мәгълүмати текстларны укырга һәм аларга күзәтү ясарга, анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтен дәлилләп белдерергә күнектерү.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Татар әдәбиятын өйрәнү өчен эчтәлек сайлау әдәбият белемендә кабул ителгән эстетик һәм әдәби принципларга бәйле.

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: мәзәк, җыр.

Төрле әдәби жанрлардагы әсәрләрдән (хикәя, повесть, роман, драма) әхлакый проблеманы үз эченә алган өзекләр.

Татар әдипләренең әсәрләре: **Г.Тукай.** «Пар ат»; **Г. Ибраһимов** «Алмачуар»; **Ш. Камал.** «Буранда»; **С. Хәким.** «Җырларымда телим», «Яратам мин»; **Ф. Кәрим.** «Бездә яздыр»; **Ф. Хөсни.** «Сөйләнмәгән хикәя»; **Ш. Маннур.** «Муса»; **Г. Афзал.** «Юл газабы», «Йөз кабат»; **М. Мәһдиев.** «Кеше китә, җыры кала»; **Ш. Галиев.** «Киңәш», «Саумы, Казан!», «Кышкы төн»; **Ф. Садриев.** «Бәхетсезләр бәхете»; **М. Әгъләм.** «Каеннар илендә», «Йөгер, каләм»; **Р. Харис.** «Ике гөл», «Күз килү», «Ак сөлге»; **Т. Миңнуллин.** «Моңлы бер җыр».

Биографик белешмәләр: **Г. Тукай, Ш. Камал, Ф. Кәрим, Г. Афзал, Ф. Садриев, М. Әгъләмов.**

Рус язучыларының тәрҗемә әсәрләре: **А. Пушкин.** «Дубровский»; **А. Куприн.** «Олеся».

Дөнья әдәбияты классикларының тәрҗемә әсәрләре: **М.Твен.** «Гекльберри Финн маҗаралары».

Прагматик текстлар: рецептлар, радио һәм телевидение программалары, белдерүләр, реклама үрнәкләре.

Эпистоляр жанр текстлары: шәхси һәм рәсми хатлар, эш кәгазьләре, котлаулар.

# 9 нчы СЫЙНЫФ (140 сәгать)

АРАЛАШУ ТЕМАЛАРЫ

1. Кешеләрнең тормышын бизәү.
2. Илләр һәм шәһәрләр.
3. Язмышыма үзем хуҗа.
4. Һөнәр сайлау.
5. Гаилә бюджеты.
6. Белем һәм китап.
7. Милли сәнгать.
8. Кеше һәм мохит.
9. Аралашу.
10. Татар әдипләре иҗатыннан.

**ЛЕКСИК МИНИМУМ**

**1. Кешеләрнең тормышын бизәү** (13 сәгать)

мәрхәмәтле, ачык йөзле, йомшак күңелле, шат күңелле, рәхмәтле, итагатьле, әдәпле, өметле, гадел, гыйлем, гыйлемле, кунакчыл, ярдәмчел, дус булырга, ихлас күңелдән, хупларга, мөһим, куркырга, ялгышырга, тыелырга, ия булырга

**2. Илләр һәм шәһәрләр** (13 сәгать)

Берләшкән Милләтләр оешмасы, Америка Кушма Штатлары, Бөекбритания, Якын Көнчыгыш, Ерак Көнчыгыш, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Төркия, Истанбул, Һиндстан, Кытай, Мисыр, Әфганстан, Үзбәкстан, Әрмәнстан, өлкә, Мәскәү, Чиләбе, Төмән, Ижевск, Әстерхан

**3. Язмышыма үзем хуҗа** (13 сәгать)

юнәлеш, язмыш, хезмәт итәргә, Россия Федерациясе Кораллы көчләре, ихтыяр көче, ихтыярлы, таләпчән, тыйнак, хөрмәт яуларга, зыялы, абруйлы, тәртипле, тотрыклы, үрнәк булырга, инанырга, түзәргә

**4. Һөнәр сайлау** (13 сәгать)

һөнәр иясе, хезмәткәр, хезмәттәш, оешма, осталык, мөмкинлек, үзенчәлекле, хыял, хыялланырга, очучы, хәбәрче, мөхәррир, алтын куллы, сүзеңдә торырга, канәгать калырга, югары белем, һөнәри белем, кирәкле

**5. Гаилә бюджеты** (13 сәгать)

хезмәт хакы, арттырырга, тоткарларга, вакытында, җитәргә (хватать), айлык, еллык, матди, акчаны белеп тотарга, исәпләргә, тукла-

нырга, вак-төяк, кием-салым, бурыч, бурычка бирергә, бурычка алырга, түләүле, түләүсез, очраклы

**6. Белем һәм китап** (13 сәгать)

кулъязма, елъязма, теркәргә, тупларга, басма (издание), махсус, фәнни-техник, фәлсәфи, тирән эчтәлекле, төшенергә, фикер алышырга, фикердәш, әзерлекле, гаять, мәгънә, ачыктан-ачык

**7. Милли сәнгать** (13 сәгать)

халык иҗаты, эшкәртергә, күн, ясарга, келәм, бизәргә, асылташ, музыка коралы, курай, гөслә, гармун, көй, моң, моңлы, серле, дәртле, җәүһәр, мәхәббәт казанырга, гашыйк булырга, таң калдырырга, дастан, бәет, каһарман, кыйсса

**8. Кеше һәм мохит** (13 сәгать)

тирә-юнь, мохит, табигать кочагы, җир-су, елга-урманнар, кош-корт, тереклек, буйсындырырга, чыганак, калдыклар, үле, туфрак, ки-сәргә, яндырырга, юкка чыгарга, югалту, аянычлы, коточкыч, җавапка тартырга, кимергә, кубәергә

**9. Аралашу** (13 сәгать)

аралашырга, эшлекле аралашу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, ки-лешү, табигыйлек, кәеф күтәрергә, тәэсир итәргә, уртак, уртаклашыр-га, шатлык, кайгы, шәхси тормыш, бер-береңне аңларга, мактарга, ачуланырга, рәнҗетергә, түбәнсетергә, зарланырга, каршы куярга, әдәпсезлек, усаллык

**10. Татар әдипләре иҗатыннан** (23 сәгать)

хис-тойгы, охшарга тырышу, тәрбияви, җанлы сөйләм, акыл хә-зинәсе, рухи дөнья, аңлаешлы, таныштырырга, үткен телле, күңелгә ятышлы, батырлыкка барырга, хезмәт сөяргә, уен-көлке, бизәлеш

## ГРАММАТИК МИНИМУМ

1. Гади һәм кушма җөмләләрне дөрес кулланырга өйрәтү.
2. Теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану күнекмәләре булдыру.
3. Иярченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив булган аналитик һәм синтетик төрләрен, аларга хас бәйләүче чараларны һәм рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү.
4. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую һәм аларны тиешле интонация белән әйтү күнекмәләре булдыру.
5. Сөйләмнең иң зур берәмлеге — текст турында мәгълүмат бирү.

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

Өч минутлык текстны тыңлап, аның төп эчтәлеге турында үз фи-кереңне белдерү;

лексик темаларга караган яңалыкларны, вакытлы матбугат язмаларын тыңлап, аларның эчтәлеген башкаларга җиткерү.

### Диалогик сөйләм

Күмәк сөйләшү (полилог) күнекмәләренә ия булу;

аралашу барышында коммуникатив максатка ирешү;

тәкъдим ителгән ситуация буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 12 дән ким булмаска тиеш).

### Монологик сөйләм

Эзлекле һәм аңлаешлы, грамматик яктан дөрес сөйләм булдыру (җөмләләр саны 14 тән ким булмаска тиеш);

монологик сөйләмдә фикерне төгәл һәм эзлекле белдерү;

укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген аңлап, авторның позициясен аңлату һәм анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтеңне белдерү.

### Уку

Фәнни-популяр, публицистик, әдәби текстлар белән танышып, алардагы әһәмиятле мәгълүматны табып әйтү;

әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрне сәнгатьле итеп уку һәм образлы итеп кабул итү;

татар әдипләренең иҗаты турында сөйләү;

татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып, үз фикереңне әйтү.

### Язу

Эшләрне грамоталы, эзлекле итеп язу;

текстларны русчадан татарчага язмача тәрҗемә итү;

рәсми кәгазьләрне (гариза, белдерү, белешмә, эшлекле хат) дөрес язу.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУ

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары**:

1) татар әдәбияты әсәрләре аша укучыларны татар халкының тарихы, рухи казанышлары, тормыш-яшәеш үзенчәлекләре белән таныштыру;

2) укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен һәм осталыкларын камилләштерү, фикер эшчәнлеген үстерү, татар телен укытуның сыйфатын яхшырту;

3) татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр һәм аларның авторлары турында мәгълүматлы булу;

4) гомумкешелек әхлакый сыйфатлар тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның дөньяга карашын формалаштыру, аларда уңай сыйфатлар булдыру, әдәбиятка кызыксынуларын арттыру;

5) танылган язучы һәм шагыйрьләрнең иҗаты, тормыш юлы турында кыскача белешмә бирү;

6) вакытлы матбугат язмаларын, мәгълүмати текстларны укырга һәм аларга күзәтү ясарга, анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтеңне дәлилләп белдерергә күнектерү.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Татар әдәбиятын өйрәнү өчен эчтәлек сайлау әдәбият белемендә кабул ителгән эстетик һәм әдәби принципларга бәйле.

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: бәет, мөнәҗәт.

Төрле әдәби жанрлардагы әсәрләрдән (хикәя, повесть, роман, драма) әхлакый проблеманы үз эченә алган өзекләр.

Татар әдипләренең әсәрләре: **Г. Тукай.** «Татар кызларына», «И, каләм»; **Г. Ибраһимов.** «Сөю — сәгадәт», «Татар хатыны ниләр күрми»; **Ф. Әмирхан.** «Хәят»; Г. Камал. «Беренче театр»; **Ә. Еники.** «Әйтелмәгән васыять»; **Г. Әпсәләмов.** «Ак чәчәкләр»; **А. Гыйләҗев.** «Җомга көн кич белән»; **Г. Афзал.** «Өф-өф итеп», «Мыек борам»; **Р. Мингалим.** «Сап-сары күзләр», «Сөйләшәсе һаман алда сыман»; **Р. Әхмәтҗанов.** «Сандугач керде күңелгә», «Әкияттән», «Әнкәй, мин монда»; **Ш. Хөсәенов.** «Әни килде».

Биографик белешмәләр**: Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, А. Гыйләҗев, Г. Камал, Ш. Хөсәенов, Р. Мингалим.**

Рус язучыларының тәрҗемә әсәрләре: **А. Пушкин.** «Пәйгамбәр»; **А. Чехов.** «Ионыч»; **К. Паустовский.** «Аннушка».

Дөнья әдәбияты классикларының тәрҗемә әсәрләре: **Р. Стивенсон.** «Хәзинәләр атавы».

Прагматик текстлар: рецептлар, радио һәм телевидение программалары, белдерүләр, реклама үрнәкләре.

Эпистоляр жанр текстлары: шәхси һәм рәсми хатлар, эш кәгазьләре, котлаулар.

## 10 нчы СЫЙНЫФ (105 сәгать)

АРАЛАШУ ТЕМАЛАРЫ

1. Татарстан Республикасының халыкара мөнәсәбәтләре (5 сәгать).
2. Чит илләрдәге татарлар (5 сәгать).
3. Телләр белгән — илләр белгән (5 сәгать).
4. Татарстан Республикасының Милли китапханәсе (5 сәгать).
5. Татар матбугаты (5 сәгать).
6. Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары (5 сәгать).
7. Сынлы сәнгать (5 сәгать).
8. Асылташлар дөньясында (5 сәгать).
9. Эш кәгазьләре (5 сәгать).
10. Халыкка багышланган гомер (5 сәгать).
11. Татар әдипләре иҗатыннан (55 сәгать)

## 11 нче СЫЙНЫФ (105 сәгать)

АРАЛАШУ ТЕМАЛАРЫ

1. Югары белем (5 сәгать).
2. Татарстанның фәнни казанышлары (5 сәгать).
3. Һөнәр сайлау (5 сәгать).
4. Ял итү һәм спорт (5 сәгать).
5. Татар музыка сәнгате һәм фестивальләр (5 сәгать).
6. Татарстан радиосы һәм телевидениесе (5 сәгать).
7. Татарстан музейлары (5 сәгать).
8. Тарихка сәяхәт (5 сәгать).
9. Татарстанның истәлекле урыннары (5 сәгать).
10. Халыкка багышланган гомер (5 сәгать).
11. Татар әдипләре иҗатыннан (55 сәгать).

### ТЕЛ МАТЕРИАЛЫН ҮЗЛӘШТЕРҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

1. Татар сөйләмен фонетик яктан дөрес оештыру.
2. Татар телендә сүз басымының үзенчәлекләрен белү һәм аерым грамматик формалардагы сүзләрдә басымны дөрес кую.
3. Сөйләмдә иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тоту: *кук — күге, кунак — кунагы, тап — таба, тек әле — тегәле.*

4. Хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне дөрес интонация белән әйтү.

5. Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне, шул исәптән кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне, дөрес куллану һәм язу.

6. Антоним, синоним, омонимнарны сөйләмдә урынлы куллану.

7. Татарча-русча, русча-татарча һәм башка төр сүзлекләрдән файдалану.

8. Лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәләрен, башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен белү.

9. Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белү: татар телендә исемнең род категориясе булмавы һәм аның лексик берәмлекләр белән бирелеше; татар телендә исемнең тартым категориясе булуы һәм аның рус телендә бирелеше; татар телендә хикәя фигыльнең заман формаларының мәгънәви үзенчәлекләре; татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавы һәм аның аналитик формалар белән бирелеше; татар телендә сыйфатның сыйфатланмыш белән ярашмавы; бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә сүздән соң килүе; татар сөйләмендә кисәкчәләрнең препозитив *(иң,үтә, тома, шыр, әллә)* һәм постпозитив (*түгел, бит, инде, әле,гына/генә, кына/кенә, ук/үк)* булуы; татар телендә саннарның һәм сыйфатларның исем янында килеш белән төрләнмәве (*өч малайда — у трёх мальчиков; бишенче сыйныфта — в пятом классе; җиде баланың — у семи детей; матур бинада — в красивом здании);* микъдар саны белән янәшә килгәндә, исемнәрнең сан белән төрләнмәве.

10. Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чараларны гамәли куллана белү.

11. Татар телендәге хикәя җөмләнең хәбәр белән тәмамлану үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыра алу.

12. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белү. *(Бүген безгә **кунаклар** килә. Кунаклар безгә **бүген** килә. Кунаклар бүген **безгә** килә.)*

13. Иярченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив кулланыла торган төрләреннән файдалана алу. Синтетик иярчен җөмләләрнең һәрвакыт баш җөмлә алдыннан килү үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыра алу.

14. Бер үк фикерне төрле синтаксик калыплар белән белдерә алу.

15. Язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куя белү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модаль сүзләр, тиңдәш кисәкләр янында, кушма җөмләдә тыныш билгеләре (өтер, ике нокта, сызык).

## СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

### Тыңлап аңлау

Җанлы сөйләмне тыңлап аңлап, күмәк сөйләшүдә катнашу; тыңланган мәгълүматны аңлатып бирү.

## Диалогик сөйләм

Аралашканда, төрле репликалардан (сораштыру, кабатлап сорау, тәкъдим итү, риза булу һ.б.) урынлы файдалану;

әңгәмәдәшнең социаль хәлен исәпкә алып, сөйләшү оештыру;

аралашу барышында фикерне төгәл җиткерү;

киңәйтелгән репликалар кулланып, сөйләшү үткәрү;

укылган текстларның эчтәлеге буенча бәхәсләрдә катнашу, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү;

укылган әдәби әсәрләрнең эчтәлеге буенча әңгәмә кору.

## Монологик сөйләм

Төрле җөмлә калыпларын урынлы кулланып, мөһим вакыйгалар, дөнья яңалыклары турында хәбәр итү һәм аларга карата үз мөнәсәбәтеңне һәм фикерләреңне белдерү;

сөйләм нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән бәйләнешле текст төзү, сөйләмне эзлекле һәм аңлаешлы итеп оештыру;

татар классик әдипләренең тормышы һәм иҗаты турында сөйләү;

әдәби әсәрләрдә күтәрелгән проблемаларны аңлау һәм үз фикерләреңне әйтү;

әсәрдәге геройларны характерлап, алар турында фикер әйтү.

## Уку

Уку төрләреннән файдаланып, тексттан кирәкле мәгълүматны табу һәм аның эчтәлеген телдән яки язмача белдерү;

текст белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләренә ия булу;

шигъри текстларны яттан сөйләү;

автор позициясен, геройларның теге яки бу эш-гамәленә нигез булган мотивларны һәм конфликтның асылын ачыклау;

татар һәм рус телләрендәге әдәби әсәрләрнең уртак һәм милли үзенчәлекләрен билгеләү, әхлакый кыйммәтләрне чагыштырып бәяләү;

татар әдәбияты классикларын һәм аларның танылган әсәрләрен әйтеп бирү;

аерым автор һәм аның әсәрләре, татар әдәбияты турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, Интернет аша табу.

## Язу һәм язма сөйләм

Аралашу ситуациясенә карата фикерләрне язмача белдерү;

өйрәнелгән темага яки укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, сочинение язу;

укылган яки тыңланган текстның планын төзеп, аның эчтәлеген язмача сөйләп бирү;

тәкъдим ителгән темага реферат язу.

# 10 нчы СЫЙНЫФ

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУ

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары:**

1) матур әдәбият текстларын кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны белү; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;

2) гуманлык карашлары, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, татар әдәбиятына, татар халкының рухи һәм мәдәни кыйммәтләренә ихтирам тәрбияләү;

3) телдән һәм язма сөйләм аша әдәби зәвык үстерү;

4) татар классик әдәбияты, балалар әдәбияты, хәзерге татар әдәбиятының күренекле вәкилләрен атый белү, аларның әсәрләреннән өзекләрнең эчтәлеген аңлау һәм фикер алыша белү;

5) татар халкының әдәбияты, тарихы, мәдәнияте буенча мәгълүматлы булу;

6) татар сәнгатенең күренекле вәкилләре турында хәбәрдар булу.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Халык авыз иҗаты үрнәкләре: легендалар, риваятьләр.

Сүз сәнгатенең барлык жанрларына да кагылган күренекле татар әдипләренең әсәрләреннән (хикәя, шигырь, поэма, повесть, роман) өзекләр:

**Дәрдемәнд .** «Каләмгә Хитаб» (Каләмгә эндәшү), «Шагыйрьгә», «Кояшның нурлары»; **С. Рәмиев.** «Авыл», «Уку», «Сызыла күңел»; **Г. Тукай.** «Мәхәббәт», «Шагыйрь», «Хөррият хакында»; **Г. Исхакый.** «Кәләпүшче кыз», «Остазбикә»; **К. Тинчурин.** «Сүнгән йолдызлар»; **М. Хәбибуллин.** «Кубрат хан»; **А. Гыйләҗев.** «Ягез, бер дога»; **И. Юзеев.** «Гашыйклар тавы»; **Р. Харис.** «Сабантуй», «Чулпы», «Ак сөлге»; **Р.Фәйзуллин.** «Яшь чак», «Туган ягым», «Яран гөл»; **Зөлфәт.** «Колын», «Тылсым», «Дүрт җыр»; **З. Хәким.** «Кишер басуы»; **Р. Зәйдулла.** «Төнге әкият», «Кизләү».

Татар халкының сәнгате, тарихы, мәгърифәт үсешен чагылдырган мәгълүмати материаллар. Вакытлы матбугат язмалары. Прагматик һәм эпистоляр жанр текстлары.

# 11 нче СЫЙНЫФ

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУ

Татар әдәбиятын укытуның төп **максатлары:**

1) матур әдәбият текстларын кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны белү; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;

2) гуманлык карашлары, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, татар әдәбиятына, татар халкының рухи һәм мәдәни кыйммәтләренә ихтирам тәрбияләү;

3) телдән һәм язма сөйләм аша әдәби зәвык үстерү;

4) татар классик әдәбияты, балалар әдәбияты, хәзерге татар әдәбиятының күренекле вәкилләрен атый белү, аларның әсәрләреннән өзекләрнең эчтәлеген аңлау һәм фикер алыша белү;

5) татар халкының әдәбияты, тарихы, мәдәнияте буенча мәгълүматлы булу;

6) татар сәнгатенең күренекле вәкилләре турында хәбәрдар булу.

## ӘДӘБИЯТ УКЫТУНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Халык авыз иҗаты үрнәкләре: дастаннар.

Сүз сәнгатенең барлык жанрларына да кагылган күренекле татар әдипләре әсәрләреннән (хикәя, шигырь, поэма, повесть, роман) өзекләр:

**Һ. Такташ.** «Мәхәббәт тәүбәсе»; **М. Җәлил.** «Хуш, акыллым», «Кошчык», «Бүреләр»; **Г. Кутуй.** «Тапшырылмаган хатлар»; **Ф. Әмирхан.** «Шәфигулла агай»; **М. Әмир.** «Агыйдел»; **Г. Әпсәләмов.** «Алтын йолдыз»; **Х. Туфан.** «Кайсыгызның кулы җылы?», «Илдәниләр бар икән?», «Луиза»; **М. Мәһдиев.** «Бәхилләшү»; **Ф. Хөсни.** «Утызынчы ел»; **И. Юзеев.** «Очты дөнья читлегеннән», «Мәңгелек белән очрашу», «Өчәү чыктык ерак юлга...»; **Т. Миңнуллин.** «Әлдермештән Әлмәндәр»; **М. Хәсәнов.** «Язгы аҗаган»; **Р. Вәлиев.** «Кыңгырау», «Сөембикә»; **Р. Гаташ.** «Ирләр булыйк», «Укытучы»; **Р. Зәйдулла.** «Битлек».

Татар халкының сәнгате, тарихы, мәгърифәт үсешен чагылдырган мәгълүмати материаллар.

Вакытлы матбугат язмалары.

Прагматик һәм эпистоляр жанр текстлары.

## УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ НОРМАЛАРЫ

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшереп бару һәм бәяләү укытуның әһәмиятле өлешен тәшкил итә. Тикшерүнең төп максаты — укучыларның белем һәм сөйләм күнекмәләрен даими күзәтеп бару, дөрес һәм гадел бәя бирү. Ә бу үз чиратында укучының кайсы теманы яхшы үзләштерүен яисә җитәрлек дәрәҗәдә үзләштерә алмавын күрсәтә, укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген яхшыртуга китерә. Тикшерүнең төп объекты укучыларның программа таләпләренә туры китереп үзләштерелгән белем һәм аралашу күнекмәләреннән гыйбарәт. Тикшерүне методик яктан дөрес оештыру шартларының берсе — тикшерү вакытында укучыларга тәкъдим ителгән эшләрнең катлаулылыгы ягыннан мөмкин кадәр бердәй булуы.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшерү эшен системалы үткәрү максатыннан, чирек барышында ***агымдагы, тематик*** һәм ***йомгаклау*** характерындагы тикшерү эшләре үткәрелә. Алар укытучыга чирек билгесен дөрес чыгарырга ярдәм итә. Шуны да әйтергә кирәк: тикшерү эшен үткәргәндә, укучылар өчен тыныч шартлар тудыру, укучыларның үз-үзләрен тыныч тотулары, җавап бирүчеләргә игътибарлы булулары да бик әһәмиятле.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшерү дөрес нәтиҗә бирсен өчен, сөйләм эшчәнлегенең һәр төре буенча иң уңай ысуллардан файдаланырга кирәк.

***Тыңлап аңлау*** күнекмәләрен тикшерү биремнәре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорауларга телдән җавап бирү; бирелгән җөмләләр арасыннан тыңланган текстның эчтәлегенә туры килгәннәрен билгеләү; тыңланган текстның төп эчтәлеген сөйләп бирү һ. б.

***Диалогик сөйләм*** күнекмәләрен тикшерү биремнәре: рәсемнәргә (предметларга) карата сораулар кую; сорауларга җавап бирү; лексик тема яки бирелгән ситуация буенча кечкенә диалоглар төзеп сөйләү; дәреслектәге диалогларны яттан сөйләү; укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча сөйләшү үткәрү.

***Монологик сөйләм*** күнекмәләрен тикшерү биремнәре: предметны (табигатьне, шәһәрне, кешеләрне) тасвирлау; лексик тема буенча хикәя төзеп сөйләү; укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләп бирү.

***Уку*** күнекмәләрен тикшерү биремнәре: текстны тулысынча аңлап һәм сәнгатьле итеп кычкырып яки эчтән уку; төрле жанрлардагы текстларны укып, кирәкле мәгълүматны табу; әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрне уку һәм эчтәлегенә карата үз мөнәсәбәтеңне белдерү.

***Язу*** һәм ***язма сөйләм*** күнекмәләрен тикшерү биремнәре: аерым сүзләрне, җөмләләрне, бәйләнешле текстны үзгәрешсез яки үзгәрешләр кертеп күчереп язу; нокталар урынына кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне (текстны) күчереп язу; сүзләрне хәтердән язу, диктант язу. Башлангыч сыйныфларда изложение һәм сочинение өйрәтү эшләре буларак кына кулланыла.

Санап чыккан алымнардан тыш, укучыларның белем һәм сөйләм күнекмәләрен тикшерү өчен, тестлар, шул исәптән компьютер тестлары куллану файдалы. Тест куелган сорауга бирелгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алудан гыйбарәт. Тестларның уңайлыгы шунда: алар тикшерү эшен тиз һәм төгәл оештыруны тәэмин итә.

Башка тикшерү чараларыннан аермалы буларак, компьютер тестларына түбәндәге өстенлекләр дә хас:

— тикшерү үткәрүне техник яктан күпкә җиңеләйтү;

— барлык укучыларга да бер типтагы биремнәр тәкъдим итү һәм аларның тиз кабул ителүе;

— нәтиҗәләрне объектив рәвештә бәяләү;

— тикшерү үткәрүче укытучының субъектив фикерен исәпкә алмау;

— тел һәм сөйләм материалын максималь дәрәҗәдә куллану;

— төрле төркемнәрдәге укучыларның белем дәрәҗәләрен чагыштырып анализлау;

— тестларны кәгазьдә бастырмау һәм кулдан тикшермәү.

Моннан тыш, компьютер тестларының тагын берничә уңай ягын ассызыклап үтәргә кирәк: беренчедән, укучылар, сынау бетүгә үк, аның нәтиҗәләрен, ягъни җыйган балларының санын һәм үз билгеләрен белә алалар; икенчедән, компьютер һәр укучының белем дәрәҗәсе турындагы оператив мәгълүматны ачык күрсәтә һәм башкалар да моның белән таныша ала, ягъни тикшерү нәтиҗәләре үтә күренмәле була. Педагогик тикшерү чарасы буларак, компьютер тестларыннан файдалану татар теленнән белем бирүнең эчтәлеген яңартуга юнәлдерелгән җитди адым булып тора.

## ТЕЛДӘН ҖАВАП БИРҮНЕ ТИКШЕРҮ

Рус телле балаларның телдән сөйләм күнекмәләрен, аралашу осталыкларын тикшерү — иң мөһим эшләрнең берсе. Телдән җавап бирүне тикшергәндә, укытучы турыдан-туры укучының үзе белән эш итә, ә бу исә баланың шәхси үзенчәлекләрен, белем һәм

сөйләм күнекмәләренең ни дәрәҗәдә үсеш алуын, өйрәнелгән тел берәмлекләреннән, җөмлә калыпларыннан файдалана белүен күзалларга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта телдән җавап бирүне тикшерү укытучыдан зур осталык та таләп итә. Ул, барыннан да элек, укытучының сораулар бирә белүе белән бәйле, чөнки укучылар белән сөйләшү үткәрү телдән җавап бирүне тикшерүнең төп өлешен тәшкил итә. Агымдагы контроль барышында укытучы, алдагы дәресләрдә өйрәнелгән тел һәм сөйләм материалы белән бәйләп, сораулар бирергә тиеш. Болай эшләгәндә, укучылар алда үткәннәрне кабатларга өйрәнәләр.

Укучыларның телдән җавап бирү күнекмәләрен тикшергәндә, сораудагы һәр сүзнең укучыга аңлаешлы булуы мөһим. Сораулар биргәндә, укуның шушы чорында балаларга аңлашылмаган сүзләрне кулланырга ярамый. Сорауның артык озын булуы да аны аңлауны кыенлаштыра, шуңа күрә укучыларга бирелергә тиешле сораулар алдан ук уйланылырга тиеш. Сыйныфтагы барлык укучылар да яхшы төшенсен өчен, сорауны ашыкмыйча һәм ачык итеп әйтергә кирәк.

Укучыларның җавабын тыңлый белү — телдән җавап бирүне тикшерүнең икенче әһәмиятле ягы. Күп кенә укытучылар, балаларның җавапларын тыңлаганда, аларны төрле сораулар белән бүлдерәләр. Бу исә укучыга кире тәэсир ясый, чөнки ул каушап кала һәм белгәнен дә сөйли алмый. Шуңа күрә укытучы баланың җавабын тыңлап бетерергә, шуннан соң гына өстәмә сораулар бирергә тиеш. Укучы озын паузалар ясап җавап бирсә яки ачыктан-ачык читкә китсә генә, укытучының катнашуы урынлы була.

Укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерү фронталь рәвештә дә оештырылырга мөмкин. Беренчедән, фронталь тикшерү укучылар белән күбрәк аралашырга мөмкинлек бирә; икенчедән, бу вакытта укучыларның белемнәре гомумиләштерелә; өченчедән, тикшерү эше тагын да җанлана төшә.

Укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшергәндә һәм бәяләгәндә, билге җавапның сыйфатына карап һәм түбәндәге таләпләрне искә алып куелырга тиеш:

1) сөйләмнең орфоэпик, лексик һәм грамматик яктан дөреслеге һәм төгәллеге;

2) сөйләмнең эчтәлеге ягыннан тулылыгы һәм эзлеклелеге;

3) сөйләмнең аңлаешлылыгы;

4) сөйләмдә сүз байлыгы, җөмлә калыпларының төрлелеге.

Укучының җавабын бәяләгәндә, укытучы, аның уңай һәм кимчелекле якларын әйтеп, киләчәктә нәрсәгә игътибар итәргә кирәклеген дә ассызыкларга тиеш.

**Йомгаклау билгесе** чирек һәм уку елы ахырында куела. Ул беренче чиратта укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен, татар телендә аралаша алу осталыгын, шулай ук язма эшләрнең нәтиҗәләрен исәпкә алып куелырга тиеш.

## БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен телдән һәм язмача тикшерү эшләренең күләме:

| № | Эш төрләре | Сыйныфлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Тыңлап аңлау | — | 0,5—1 мин | 1—1,5 мин | 1,5—2 мин |
| 2. | Диалогик сөйләм | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 3. | Монологик сөйләм | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 4. | Язу: 1) күчереп язу (җөмлә саны)<br>2) сүзлек диктанты (сүзләр саны)<br>3) диктант (сүзләр саны)<br>4) изложение (сүзләр саны)<br>5) сочинение (җөмлә саны) | 1—2 | 3—4<br>6—7<br>25—30 | 5—6<br>8—9<br>30—35<br>40—45<br>6—7 | 7—8<br>10—12<br>35—40<br>50—55<br>7—8 |

### Тыңлап аңлауны бәяләү

Тыңланган татар сөйләмен тулаем аңлап, төп эчтәлеген сөйләп бирә алганда, **«5»ле** куела.

Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген якынча дөрес сөйли алганда, **«4»ле** куела.

Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген өлешчә генә сөйли алганда, **«3»ле** куела.

Тыңланган татар сөйләменең эчтәлеген тулаем аңламаганда, **«2»ле** куела.

### Диалогик сөйләмне бәяләү

Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, **«5»ле** куела.

Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2—3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, **«4»ле** куела.

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4—6 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлексез диалогик сөйләм төзегәндә, **«3»ле** куела.

Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча диалог төзи алмаганда, **«2»ле** куела.

### Монологик сөйләмне бәяләү

Әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен **«5»ле** куела.

Аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2—3 хатасы булган, эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм өчен **«4»ле** куела.

Сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4—6 хаталы, эчтәлеге ягыннан эзлекле булмаган монологик сөйләм өчен **«3»ле** куела.

Лексик темага монолог төзи алмаганда, **«2»ле** куела.

**Укуны бәяләү**

Текстның эчтәлеген тулаем аңлап, сәнгатьле итеп укыганда, **«5»ле** куела.

Текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда, әмма 2—3 орфоэпик хата (авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, интонацияне сакламау) булганда, **«4»л**е куела.

Текстның эчтәлеген өлешчә аңлап укыганда, 4—6 тупас орфоэпик хата булганда, **«3»ле** куела.

Текстның эчтәлеген тулысынча аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләрне бозып укыганда, **«2»ле** куела.

**Язма эшләрне тикшерү**

Башлангыч мәктәптә, укучыларның телдән сөйләм күнекмәләре белән бергә, язу һәм язма сөйләм күнекмәләре дә үсеш алырга тиеш. 1 нче сыйныфта балалар баш һәм юл хәрефләрен, кыска сүзләрне һәм җөмләләрне күчереп язарга күнегәләр. Укучыларның язу күнекмәләрен тикшергәндә, мондый күләмне истә тотарга кирәк: 1 нче сыйныфта 1 юл; 2 нче сыйныфта 2 юл; 3 нче һәм 4 нче сыйныфларда 4 юл.

2—4 нче сыйныфларда татар теленнән язма эшләр ике төркемгә бүленә:

1) өйрәтү эшләре (изложение, сочинение);

2) контроль эшләр (күчереп язу, сүзлек диктанты, диктант).

1—2 нче сыйныфларда аерым җөмләләрне яки бәйләнешле текстны үзгәрешсез күчереп язу таләп ителсә, 3—4 нче сыйныфларда сүзләрне кирәкле формада куеп яки ноктлар урынына туры килгән сүзләрне куеп күчереп язу эшләре кулланыла.

Диктант яздыру өчен, төрле характердагы тел материалы (аерым сүзләр, аерым җөмләләр, бәйләнешле текст) сайланырга мөмкин. Диктант яздыру өчен сайланган бәйләнешле текст уртача авырлыкта, эчтәлеге һәм грамматик төзелеше ягыннан укучыларга аңлаешлы булырга тиеш, ә инде үзләштерелмәгән сүзләр очраса, укытучы аларны тактага язып аңлата.

Укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен тикшергәндә, эчтәлекнең тулылыгына һәм эзлеклелегенә, җөмлә калыпларының грамматик яктан дөреслегенә һәм төрлелегенә игътибар итәргә кирәк. Язма эшләрнең эчтәлеген бәяләү белән беррәттән, укытучы орфографик һәм пунктуацион хаталарны да төзәтергә тиеш. Күп эшләрдә бер үк төрле хата кабатланса, бу кагыйдәне тагын бер тапкыр аңлату һәм дәрестә аңа махсус тукталу сорала. Әгәр дә хаталар индивидуаль характерда булса, укучылар белән шәхси эш алып барырга кирәк.

1—2 нче сыйныфларда орфографик хаталарга гына игътибар ителсә, 3—4 нче сыйныфларда пунктуация хаталары да исәпкә алына. Хәрефне төшереп калдыру, кирәкмәгән хәреф өстәп яки хәрефләрне

алыштырып язу, сүзне юлдан-юлга дөрес күчермәү орфографик хатага карый. Әгәр дә сүз берничә урында дөрес, ә аерым бер урында хаталы язылган икән, бу ялгыш дип саналмый. Бер үк хата берничә сүздә кабатланса, бу бер ялгыш дип исәпләнә.

Тикшерү характерындагы язма эшләр, программаның иң әһәмиятле бүлекләрен үткәч, чирек яки уку елы ахырында уздырыла, һәм укучыларның билгеләре сыйныф журналына куела. Өйрәтү характерындагы язма эшләргә килгәндә, аларның санын һәм төрләрен укытучы үзе билгели, һәм бу очракта сыйныф журналына бары тик уңай билгеләр генә куела.

**Контроль күчереп язуны бәяләү**

Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә **«5»ле** куела.

Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1—3 төзәтүе яки 1—2 орфографик хатасы булган эшкә **«4»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4—5 төзәтүе яки 3—5 орфографик хатасы булган эшкә **«3»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә **«2»ле** куела.

**Диктантны бәяләү**

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик хаталы диктантка **«5»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылган, 2—3 орфографик хаталы диктантка **«4»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4—6 орфографик хаталы диктантка **«3»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 7 яки артыграк орфографик хаталы диктантка **«2»ле** куела.

**Язма сөйләмне бәяләү**

2—4 нче сыйныфларда укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен, өйрәтү характерындагы изложениеләр һәм сочинениеләр яздырыла. Аларны бәяләгәндә, эшнең эчтәлеге ягыннан тулы һәм эзлекле язылуы, грамоталы булуы исәпкә алына. Башлангыч сыйныфларда изложение һәм сочинениеләр өчен бер билге куела.

Эзлекле язылган, 1 орфографик һәм 1 пунктуацион яки 1 грамматик хаталы эшкә **«5»ле** куела.

Эзлекле язылган, ләкин эчтәлектә ялгыш җибәрелгән, 2—3 орфографик һәм пунктуацион яки 2—3 грамматик хаталы эшкә **«4»ле** куела.

Эзлекле язылмаган, 4—6 орфографик һәм пунктуацион яки 4—6 грамматик хаталы эшкә **«3»ле** куела.

Эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 7 дән артык орфографик һәм пунктуацион яки 7дән артык тупас грамматик хаталы эшкә **«2»ле** куела.

## ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ҺӘМ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

Телдән җавап бирү күнекмәләрен тикшерү эшләренең күләме:

| № | Эш төрләре | Сыйныфлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10—11 |
| 1. | Тыңлап аңлау (минутларда) | 2 | 2 | 3 | 3 | 3 | 4 |
| 2. | Диалогик сөйләм (репликалар саны) | 7 | 8 | 9 | 10 | 12 | 14 |
| 3. | Монологик сөйләм (фразалар саны) | 8 | 9 | 10 | 12 | 14 | 16 |

### Тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирүне бәяләү

Тыңланган текстның эчтәлеген тулаем аңлап, тәкъдим ителгән барлык сорауларга язмача дөрес җавап бирелгән, 1 орфографик хатасы яки эчтәлеккә бәйле 1 хатасы булган эшкә **«5»ле** куела.

Тыңланган текстның эчтәлеген аңлап, тәкъдим ителгән сорауларга дөрес җавап бирелгән, әмма 2—3 орфографик, 3 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 2—3 хатасы булган эшкә **«4»ле** куела.

Тыңланган текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, тәкъдим ителгән сорауларга төгәл җавап бирелмәгән, 5 орфографик, 5 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 4—5 хатасы булган эшкә **«3»ле** куела.

Тыңланган текстның эчтәлеге буенча тәкъдим ителгән сорауларга бирелгән җавапларның яртысы дөрес булмаса, 6 орфографик, 6 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 5 тән артык хатасы булган эшкә **«2»ле** куела.

### Диалогик сөйләмне бәяләү

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, **«5»ле** куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2—3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, **«4»ле** куела.

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4—6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә, **«3»ле** куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча диалог төзи алмаганда, **«2»ле** куела.

## Монологик сөйләмне бәяләү

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен **«5»ле** куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2—3 хаталы монологик сөйләм өчен **«4»ле** куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4—7 хаталы монологик сөйләм өчен **«3»ле** куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог төзи алмаганда, **«2»ле** куела.

## Укуны бәяләү

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулаем аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда, **«5»ле** куела.

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда, әмма 2—3 орфоэпик хата булганда, **«4»ле** куела.

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген өлешчә аңлап укыганда, 4—6 тупас орфоэпик хата булганда, **«3»ле** куела.

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген бөтенләй аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләрне бозып укыганда, **«2»ле** куела.

## Язма эшләрне тикшерү һәм бәяләү

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен, татар теле дәресләрендә төрле язма эшләр үткәрелә.

Рус телле укучылар өчен татар теленнән язма эшләр ике төркемгә бүленә:

1) өйрәтү характерындагы эшләр (изложение, сочинение);

2) контроль эшләр (сүзлек диктанты; хәтер, күрмә, иҗади диктантлар).

Диктант яздыру өчен, төрле характердагы материал (аерым сүзләр, аерым җөмләләр, бәйләнешле текст) сайланырга мөмкин. Диктант яздыру өчен сайланган бәйләнешле текст уртача авырлыкта, лексикасы, эчтәлеге һәм грамматик төзелеше ягыннан укучыларга аңлаешлы булырга тиеш, ә инде үзләштерелмәгән сүзләр очраса, укытучы аларны тактага яза һәм аңлата. Диктантны яздырганчы, укытучы текстны тиешле интонация белән һәм укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән темпта укып чыгарга, ә диктантны язып бетергәч, аны тикшереп чыгу өчен балаларга мөмкинлек бирергә тиеш. Язма эшләрне тикшергәндә, укытучы аларның эчтәлеген бәяли, укучыларның орфографик һәм пунктуацион хаталарын төзәтә. Күп эшләрдә бер үк төрле хата кабатланса, укытучы бу материалны тагын бер тапкыр аңлатырга тиеш. Әгәр хаталар индивидуаль характерда булса, укучылар белән шәхси эш алып барырга кирәк. Сүз берничә урында дөрес, ә аерым бер урында хаталы язылган икән, бу ялгыш дип саналмый. Бер үк хата берничә сүздә кабатланса, бу бер ялгыш дип исәпләнә.

Язма контроль эшләр өчен барлык укучыларның билгеләре сыйныф журналына куела. Өйрәтү характерындагы язма эшләргә килгәндә, сыйныф журналына бары тик уңай билгеләрне генә куярга мөмкин.

Уку елы дәвамында язма эшләрнең саны һәм төрләре укучыларның лексик-грамматик һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан чыгып билгеләнә.

**Сүзлек диктанты һәм аны бәяләү**

| Сыйныфлар | Сүзләр саны |
|---|---|
| 5 | 12—15 |
| 6 | 15—17 |
| 7 | 18—20 |
| 8 | 22—25 |
| 9 | 25—28 |
| 10 | 28—33 |
| 11 | 33—35 |

Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә **«5»ле** куела.

Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1—3 төзәтүе яки 1—2 орфографик хатасы булган эшкә **«4»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4—5 төзәтүе яки 3—5 орфографик хатасы булган эшкә **«3»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә **«2»ле** куела.

**Диктантның күләме һәм аны бәяләү**

| Сыйныфлар | Уку елы башында (сүзләр саны) | Уку елы ахырында (сүзләр саны) |
|---|---|---|
| 5 | 35— 40 | 40 — 45 |
| 6 | 45 — 50 | 50 — 55 |
| 7 | 55— 60 | 60— 65 |
| 8 | 65— 75 | 75 — 80 |
| 9 | 80— 90 | 90—100 |
| 10 | 95—105 | 105—115 |
| 11 | 110—120 | 115—125 |

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик, 1 пунктуацион хаталы диктантка **«5»ле»** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылган, 2—3 орфографик, 2—3 пунктуацион хаталы диктантка **«4»ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4—6 орфографик, 6 пунктуацион хаталы диктантка **«3»ле** куела.

Пөхтә язылмаган, 7 дән артык орфографик, 7 дән артык пунктуацион хаталы диктантка **«2» ле** куела.

## Язма сөйләмне тикшерү һәм бәяләү

Укучыларның бәйләнешле язма сөйләм күнекмәләре өйрәтү характерындагы изложениеләр һәм сочинениеләр ярдәмендә тикшерелә. Алар белән беррәттән башка язма эшләр дә кулланыла: сорауларга язмача җавап бирү; рус телендәге текстларны татар теленә язмача тәрҗемә итү; укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген язмача сөйләп бирү (изложение); бирелгән ситуация яки тәкъдим ителгән тема буенча фикерләрне язмача белдерү (сочинение) һ. б. Язма сөйләмне бәяләгәндә, эчтәлекнең тулылыгына һәм эзлеклелегенә, җөмлә калыпларының грамматик яктан дөреслегенә һәм төрлелегенә, стиль бердәмлегенә игътибар итәргә кирәк. Изложение һәм сочинение өчен ике билге куела: беренчесе — эшнең эчтәлеге өчен, икенчесе — грамоталы язуга.

## Изложениеләрне бәяләү

Изложение яздыру өчен, хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстлар яки өзекләр алына. Алар рус телле балаларга аңлаешлы булырга, аларның яшь үзенчәлекләренә туры килергә һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерүне истә тотып сайланырга тиеш.

Укылган яки тыңланган текст белән эшләү барышында укучыларның фикер йөртүләренә, текст эчтәлегеннән чыгып, нәтиҗәләр ясый белүләренә, сүз байлыгыннан һәм җөмлә калыпларыннан урынлы файдалана алуларына төп игътибар бирелә:

| Сыйныфлар | Уку елы башында (сүзләр саны) | Уку елы ахырында (сүзләр саны) |
|---|---|---|
| 5 | 55— 65 | 65— 75 |
| 6 | 70— 80 | 85— 95 |
| 7 | 90— 95 | 100—110 |
| 8 | 110—120 | 120—130 |
| 9 | 130—140 | 140—150 |
| 10 | 150—160 | 165—175 |
| 11 | 175—180 | 190—210 |

Тыңланган текстның эчтәлеге тулы, эзлекле һәм дөрес язылган, 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 1 грамматик хаталы эшкә **«5»ле** куела.

Тыңланган текстның эчтәлеге эзлекле һәм дөрес язылган, ләкин 1—2 эчтәлек ялгышы җибәрелгән, 2—3 орфографик, 2—3 пунктуацион яки 2—3 грамматик хаталы эшкә **«4»ле** куела.

Тыңланган текстның эчтәлеге өлешчә эзлекле язылган, 4—5 орфографик, 4 пунктуацион яки 4—5 грамматик хаталы эшкә **«3»ле** куела.

Тыңланган текстның эчтәлеге бөтенләй ачылмаган һәм эзлекле язылмаган, 6 дан артык орфографик, 5 тән артык пунктуацион яки 6 дан артык грамматик хаталы эшкә **«2»ле** куела.

## Сочинениеләрне бәяләү

Сочинение укучыларның тормыштагы күзәтүләреннән алган тәэсирләрен язмада грамоталы һәм эзлекле бирә белү, әдәби әсәрнең эчтәлеген үз сүзләре белән бәйләнешле итеп яза алу мөмкинлекләрен тикшерү максатыннан яздырыла. Алар укучыларның тел һәм әдәбият дәресләрендә алган белемнәрен ныгыту, тирәнәйтү һәм камилләштерүгә юнәлтелә.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган һәм эчтәлеге тулы ачылган, 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булган эшкә **«5»ле** куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган, ләкин 2—3 эчтәлек ялгышы, 2—3 орфографик, 2—3 пунктуацион хатасы булган эшкә **«4»ле** куела.

Тәкъдим ителгән темага өлешчә эзлекле язылган, эчтәлеге тулысынча ачылмаган, 4—5 орфографик, 4—5 пунктуацион һәм грамматик хатасы булган эшкә **«3»ле** куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хатасы булган эшкә **«2»ле** куела.

Татар теленнән белем бирүнең нәтиҗәләре турындагы мәгълүматка ия булу өчен, укытучы укучыларның телдән һәм язма күнекмәләрен даими рәвештә тикшереп бару ысулларын методик яктан дөрес билгели белергә һәм алардан уңышлы файдаланырга тиеш. Шунысын да истә тоту мөһим: тикшерү эшләре белем бирү процессының әһәмиятле өлешен тәшкил итә, чөнки укучыларның белем дәрәҗәсе белән беррәттән укытучының методик эшчәнлеге дә сынала, кулланыла торган укыту чараларының ни дәрәҗәдә уңышлы булуы да ачык күренә.